# БАЛАЛАР БАКЧАСЫНДА
# БӘЙРӘМ ИРТӘЛӘРЕ,
# КҮҢЕЛ АЧУ КИЧӘЛӘРЕ

Ютазы районы Кече Урыссуы “Ләйсән” балалар бакчасы

2019нчы ел

## “Сөмбелә бәйрәме”.

(Зал бәйрәмчә бизәлгән.)

Җырлый – җырлый Йомры икмәк килеп керә.

**Йомры икмәк:**

- Һе, кая соң болар? Үзләре бәйрәмгә чакырдылар, ә үзләре юк?!

(Шул вакыт Сөмбелә керә.)

**Йоры икмәк:**

- Сөмбелә? Син монда нишләп йөрисең?

**Сөмбелә:**

- Тукта – тукта ашыкма, Йомры икмәк, мин үземнең бәйрәмгә килдем. Ә син нишләп йөрисең?

**Йомры икмәк:**

- Ничек инде? Бу көнне мин яздан бирле көттем. Яз көне мин бөртек идем, ә менә бүген хуш исле, йомры икмәк булдым.

**Сөмбелә:**

- Дөрес әйтәсең, бу икебезнең дә бәйрәм ич!

(Җил искән тавыш ишетелә.)

**Сөмбелә:**

- Нинди рәхәт җил исә, яфракларны селкетә.

(Шулвакыт талгын көй уйный башлый. Кулларына яфрак тоткан балалар бии – бии кереп урыннарына басалар һәм яфракларын алга очырып җибәрәләр.)

**Йомры икмәк белән Сөмбелә:**

- Исәнмесез, балалар! (Исәнләшәләр.)

**Тәрбияче:**

Зифа буйлы, җитен чәчле

Зәңгәр күзле шушы кызның

Исемнәре ничек икән

Әйтегезче, кем белә?

**Балалар:**

-Сөмбелә, Сөмбелә!

**Сөмбелә:**

Ашлык булып җирдә үсә

Уңыш бит ул Сөмбелә.

Бөтен җирне нурга күмә

Кояш кебек Сөмбелә.

**Йомры икмәк:**

- Сөмбелә, кара әле, минем бөтен ашлыкларым да монда килгәннәр. Алар барысы да тук, башаклары алтын сыман.Үзләре нинди көчлеләр!

**Сөмбелә:**

- Бик яхшы. Ә син минем бакчадагы яшелчә – җимешләремә кара. Алар җәй буе яңгыр суы эчкәннәр, тулып пешкәннәр, үзләре авызга керергә торалар.

**Тәрбияче:**

- Туктагыз, тукта, дусларым, ашыкмагыз. Без сезне эштә сынап карыйк. Йомры икмәк, әйдәле синең игеннәреңне тыңлап карыйе, әле.

***Бодай:***

Игеннәрнең патшасы мин,

Алтын бөртекле бодай.

Бодай булса амбарыңда

Синең илең дә бик бай.

***Карабодай:***

Менә мин – карабодай,

Ничек үстем соң болай?

Мин бик тәмле ботка да,

Һәм бик тәмле шәп бал да**.**

***Борчак:***

Мин – борчакны, һәр бала,

Әлбәттә бик ярата.

Борчак җитешкән чакта

Басудан кайтмый ята.

**Тәрбияче:**

- Яшелчәләр, ә сез ничек җавап бирерсез икән?

***Кишер:***

Мин – кишер, алтын казык

Ашарсың казып алып.

Үстерерсең зур итеп,

Көчле һәм матур итеп.

***Кәбестә:***

Катлы – катлы үстем мин

Тәмле сулар эчтем мин.

Витамин эчем тулы,

Кәбестә шул исемем.

***Бәрәңге:***

Ә, бәрәңге, бәрәңге

Бәрәңгене күр әле.

Сап – сары бәрәңге белән

Тирән базыбыз тулды.

**Тәрбияче:**

- Сөмбелә, Йомры икмәк, сез юкка ярышасыз. Яшелчәләребез дә, игеннәребез дә бик мул, тәмле булып үскәннәр. Сез барыгыз да безнең өчен бик файдалы, бик тәмле. Әйдәге, бергәләп үзебез турында җырлыйк әле.

**Җыр “Урожайная»** (Филиппенко муз.)

1. Мы корзиночки несем,
   Хором песенку поем.

   Урожай собирай,

   И на зиму запасай!

   Ой – да, собирай

   И на зиму запасай!

2. Мы, ребята, молодцы,
   Собираем огурцы,
   И фасоль, и горох
   Урожай у нас не плох!

   Ой – да, и горох

   Урожай у нас не плох!

**Сөмбелә:**

- Менә без уңышны да җыйдык, ә хәзер безгә дуслашырга вакыт. Әйдәгез, бер дуслык биюен биеп алыйк.

**“Дуслык” биюе.**

**Тәрбияче:**

Игенченең хезмәтен

Онытмасын һәр кеше.

Ипекәй менә шундый

Тырыш хезмәт җимеше.

**Сөмбелә:**

Алдагы көннәрдә дә

Телим сезгә уңышлар.

Муллыкта, рәхәт тормышта,

Яшәгез, нәни дуслар!

- Миңа , дусларым, китәргә вакыт. Сау булыгыз!

**Балалар:**

- Сау бул, Сөмбелә!

**Йомры икмәк:**

- Ә хәзер, әйдәгез, хуш исле ипекәй белән чәй эчәргә киттек.

**“Көзге бакчада кунакта”**

***Музыка № 1*** астында балалар залга керә.

**Алып баручы.** Хәерле көн, кадерле балалар!
Хәерле көн, хөрмәтле кунаклар!
Курайларда көз көйләрен уйнап
Агачларны сары төскә буяп,
Куакларга җиләк – җимеш элеп,
Агач төпләренә гөмбә тезеп
Илем буйлап алтын көз йөри.

***Музыка № 2***
**Песня : “Осень, осень”**
Осень, осень наступила,
Листья осыпаются.
Солнца нет и потемнело,
Дождик начинается.

Припев:
Кап-кап на дорожки,
Кап-кап на ладошки.
Дождик землю поливай,
С нами поиграй.

Паучки, жучки и мошки
Прячутся, скрываются,
И в далекую дорогу
Птички собираются.

Припев.
Кап-кап на дорожки,
Кап-кап на ладошки.
Дождик землю поливай,

С нами поиграй.

**Алып баручы.**
Күз ул – бер еллык хезмәткә
Нәтиҗә ясау чоры.
Уңыш белән тула амбар –
Бу бит бәйрәмнең зуры!
Дөрестән дә кырда, бакчада эш беткәч, уйнап, күңел ачып алсак та була.

***Ишек шакыйлар.***

***<u>Музыка № 3.</u>***

**Алмабикә** (керә). Иң зур, кызыл һәм баллы -
Берәрегез беләме?
Әйе – Алмабикә патша мин,
Бәйрәмгә чакырамын.
Уңганнар һәм эшчәннәр
Иң түремә үтсеннәр.
Ярышып, уйнап-көлеп
Күңел ачып китсеннәр!

Уңыш бәйрәмен ачу өчен минем табышмакларга җавап табарга кирәк. Сез әзерме?

1. Җиргә күмәләр язын,
Көзен алалар казып.
Күмгәндә берәү була
Алганда – чиләк тула. (Бәрәңге)

2. Кызыл кызы җир эчендә,
Чәчләре җир өстендә. (Кишер)

3. Үзе бер бөртек, эче мең бөртек,
Башы – җирдә, койрыгы – коймада. (Кабак)

4. Агачта үсә,
Кызарып пешә.
Өлгергәч, җиргә
Өзелеп төшә. (Алма)

5. Менә сиңа тамаша,
Бер нәрсә ике төстә!
Кызыл гәүдәсе җирдә,
Яшел койрыгы өстә. (Кызыл чөгендер)

6. Кечкенә генә сары карт,
Кигән туны тугыз кат. (Суган)

7. Тәрәзәсе юк, ишеге юк
Эче тулы халык. (Кыяр)

8. Подставив солнышку бочок,
Лежит на грядке … .
(Кабачок)

9. Её тянут бабка с внучкой,
Кошка, дед и мышка с Жучкой.
(Репка)

10. Он бывает, дети, разный –
Жёлтый, травяной и красный.
То он жгучий, то он сладкий,
Надо знать его повадки.
А на кухне – глава специй!
Угадали? Это … .
(Перец)

**Алып баручы.** Алмабикә патша, безнең балалар бөтен табышмакларның да җавабын таптылар. Уңыш бәйрәмен башларга рөхсәт бирәсеңме?

**Алмабикә.** Бик рәхәтләнеп. Уңыш бәйрәмен җыр белән башлап җибәрик.

***Музыка №4***

**Җыр “Көз килә”** (А.Минһаҗев сүз., Р.Сәрвәров муз.)
Шаяра әле күбәләк
Үтсәләр дә җәйләре.
Ә урамга килеп керде,

Килде яфрак бәйрәме.

Кушымта:
Нинди генә төсләре юк,
Күреп исең китәрлек.
Яфрак ява, яфрак ява
Юлыбызга түшәлеп.

Өлгереп җиткән миләшләр
Утлар шикелле яна.
Ә яфраклар бөтерелеп
Ява да ява, ява.

Кушымта.

Югалмаган икән әле
Төсләрнең яшеле дә.
Ясап яфрак бәйрәмнәре
Килә көз әкрен генә.

**Раяз.** Урамнар буйлап килә
Көзбикә көлә-көлә.
Яфракларны сибә-сибә
Шаяра, уйный, көлә.

**Булат.** Урманнарда бар агачлар
Сап-сары күлмәк кигән.
Ул шулай яшел җәйдән соң
Безгә сары көз килгән.

**Эльза.** Ни арада җәй үткән
Алтын көз килеп җиткән.
Агачлар бизәлгәч,
Урман бик матур икән!

**Карина.** Наступила осень
Пожелтел наш сад.
Листья на березе
Золотом горят.

Не слыхать веселых
Песен соловья.
Улетели птицы
В теплые края.

**Динә.** Яшел куаклар буялды
Ал, яшел, сары төскә.
Көзге җил, яңгыр артыннан
Яфраклар ява өскә.

***<u>Музыка № 5</u>***

**Җыр "Яфрак бәйрәме"** (Роза Еникеева муз., Ләбиб Лерон сүз.)
Яңгыр түгел, кар да түгел,
Яфраклар ява җиргә.
Көз турында җырлыйм әле-
Кушыл син яңа җырга.

Кушымта:
Сары, сары, сап – сары
Агачның яфраклары.
Җил исә, ява яфрак-
Көзнең матур чаклары.

Оча яфрак, уйный яфрак,
Һаваларда әйләнеп.
Бүген, бүген, бүген, бүген
Яфракларның бәйрәме!

**Газ. Искәндәр.** Ашлык бик уңган
Җимеше мулдан.
Буралар тулган-
Көз бик сөенгән.
**Алып баручы.** Яз көнендә түтәллргә
Яшелчәләр утырттык.
Рәхәтләнеп үсегез, дип,
Чүпләрен утап тордык.

Сулар сиптек җәй көнендә,

Бик тырышып карадык.
Күзләр килгәч, сөенешеп
Мул уңышны санадык.

**Данил (кыяр).** Чиләк-чиләк су эчә,
Су эчерсәң, тиз үсә.
Чиләк-чиләк җыябыз,
Кышка тозлап куябыз.
**Искәндәр (помидор).** Помидор да бик файдалы,
Төп яшелчә салатта.
Тәмле генә түгел әле
Витамин күп томатта!
**Роберт (кабак).** Түтәлдә ята кабак,
Кояшка кырын карап.
Кабарам да тулам, ди,
Мин дә кояш булам, ди.
**Дарина (кишер).** Көчле, җитез булыйм дисәң,
Кишер ашап кара син.
Кишер – саулык чыганагы,
Кишердә күп коротин.
**Айваз (суган).** Суган бигрәк усал, инде,
Әрчегәнне яратмый.
Какмый, сукмый, ә шулай да
Елатканчы яңаклый.
**Алия (алма).** Яз көне тудым мин,
Җәй көне үстем мин.
Кызарып пешкәч,
Өзелеп төштем мин.

**Алмабикә.** Миңа монда чын алмаш үстергәнсез икән. Килгән кунакларга үзегезне дә күрсәтегез, инде.

***<u>Музыка № 6</u>***

**Бию “Полька овощей”.**

**Алмабикә.** Рәхмәт, сезгә балалар,
Бик тырыш һәм уңган сез.
Эш сөя барыгыз

Шуңа балкый йөзегез.

***<u>Музыка № 7</u>***

**Җыр “Безнең бакча”** (Р.Сәрвәров муз., халык сүз.)
Бар матур бакча,
Анда кишер үсә.
Менә шундый кишер зур,
Менә шундый кечкенә.

Кушымта:
Кишер, кишер, кил әле,
Биеп, биеп кит әле.
Әллә-лә, әллә-лә,
Биеп, биеп кит әле.

Бар матур бакча,
Анда кыяр үсә.
Менә шундый кыяр зур,
Менә шундый кечкенә.

Кушымта:
Кыяр, кыяр, кил әле,
Биеп, биеп кит әле.
Әллә-лә, әллә-лә,
Биеп, биеп кит әле.

**Алмабикә.** Ә хәзер Көзге аукцион башлана. Мин сораулар бирәм, ә сез җавабын әйтәсез. Кем азакы җавабын әйтә, шул җиңүче була.
1. Сез нинди яшелчәләр беләсез?
2. Сез нинди җимешләр беләсез?
3.Бакчада кирәк булган эш коралларын атагыз.

**Алып баручы.** Бәйрәм матур һәм күңелле
Музыка уйнап торса.
Сезнең җитез аяклар
Тыпырдап биеп торса.

***<u>Музыка № 8</u>***

**Танец «Барбарики».**

**Алмабикә.** Балалар, сез уйнарга яратасызмы?

**Алып баручы.** Бакчада төрле уеннар
Без гел уйнап торабыз.
Ә бүген ашарга да
Үзебез пешерәбез.

**Конкурс «Яшелчә һәм җиләк-җимешләр»**

Бу уенда 2 шәр бала катнаша. 1 бала кәрҗингә яшелчәләр, 2 бала кәрҗингә җиләк-җимеш тутыра.

**Алып баручы.** Безнең кырларда үсте
Игеннәрнең һәр төре.
Саламнары камыш кебек,
Алтын кебек бәрәңге.

***2 уен.***

**Дидактическая игра** *«Как хлеб пришел на стол»*

**Алып баручы (эти-әниләргә).** Кунакларга бик күңелсез
Булмасын бу бәйрәмнәр.
Шуңа күрә бу уенны
Бүләк итик аларга.

***3 уен.*** “Тәме буенча бел!”

***4 уен.*** “Мин башлыйм, син тәмамла” .
“Икмәк – (ил тоткасы)”
“Кем эшләми – (шул ашамый)”
“Эшләмәсәң – (җәй көне)”
“Ипинең валчыгы да (бездән зур)”
“Эш беткәч (уйнарга ярый)”

***<u>Музыка№9</u>***

**Бию-җыр “Урожайная”.**

**Алмабикә.** Рәхмәт, балалар, сез бик күп нәрсәләр беләсез. Тырыш, эшчән икәнсез, мине бик сөендердегез. Сезне Уңыш бәйрәме белән котлап, үземнем күчтәнәчләремне таратам.

Тәмам.

## “Көз бәйрәме”

Зал төсле яфраклар белән бәйрәмчә бизәлгән. Күңелле көй астында алып баручы белән балалар залга керәләр.

**Алып баручы.** Балалар без буген сезнең белән елда утэ торган көз бәйрәменэ жыелдык.Карагыз әле, бүген безнең залыбызда ничек якты һәм матур. Тирә-юньдә төсле матур яфраклар янып тора. Бүген безгә бәйрәм килгән.

Әйе, бүген Көз бәйрәме!
Яфракларны күр әле:
Алтын төскә кергәннәр,
Бар дөньяны күмгәннәр!
Җил чыкканда шаулашалар,
Оча-оча уйнашалар,

Һавада әйләнәләр...
"Яфрак бэйрэме" жыры (Р. Еникеева музыкасы , Л. Лерон сүзләре)
1бала.  Менә көз килде
Салкынча җилле.
Агачларда яфраклар
Саргайган инде.
2бала. Көзге урман тып-тын булган,
Агач башы ялангач.
Соңгы яфрак төшә калтырап,
Әз генә җил шаяргач.
3 бала. Көз килде, уңыш булды,
Табын сый белән тулды.
Рәхим итегез, дуслар,
Көзге бәйрәмгә!
4бала.  Бик күңелле урамда-
Алтын-сары бар дөнья,
Җил яфраклар биетә,
Көз шатлана, туй итә
5 бала.  Көз җиттеме, бар агачлар
Алтынга манган сыман.
Кызыл яфраклы чаганнар
Утларда янган сыман.
6 бала.  Көз җиттеме, җир өстенә
Алтын яфрак җәелә.
Карап туеп булмый һич тә
Бу фасылның яменә.
“Көз” җыры  башкарыла (М.Әндерҗанова сүзләре һәм көе).
Алып баручы.Көзге матур бер көндэ
Куян йөгергән өенә
Аланнар буйлап та ,болыннар буйлап та
Кәрзинендә булган диТөрледән — төрле гөмбә.
Куян :Бүген иртән әни миңа
Кушты гөмбэ җыярга
Хәр гөмбәне кәрзинемә
Кирәк салып куярга.
Гөмбә булып киенгән балалар янына куян бара.
Ак гөмбә: Без-ак гөмбә
Без-батыр гөмбә,
Курыкмыйбыз беркемнән дә,

Менә нинди кыю гөмбә.
**Гөрәждә** : Без гөреждә гөмбәләре
Бертөсле бөтенебез.
Безне табу кыен түгел
Урман юлыннан эзләгез.
**Баллы гөмбә**:Мин баллы гөмбә
Үсәм көндез һәм төнлә.
**Куян:** Ай, нинди сез матур бүген урман да ,
Мин телим хәзер барыгызны да җыярга.
“Гөмбә җыябыз” эстафетасы уздырыла. Идәнгә төрле гөмбә муляжлары (яисә гөмбә рәсеме ясалган карточкалар) куела. Балалар 2 төркемгә бүленәләр. Һәр төркемдә әйдәүче билгеләнә, аларга кәрзиннәр бирелә. Тәрбияче сигналы буенча һәр ике төркемдәге балалар гөмбә җыя башлыйлар. Алар кәрзингә ашарга яраклы гөмбәләрне генә салырга тиешләр. Ахырдан һәр ике төркемнең кәрзине тикшерелә. Гөмбәләрне тиз һәм иң күп җыйган төркем җиңүче була .
**Алып баручы**. Менә безгә кунакkка Куян да килеп китте. Ә безнең бәйрәмебезнең төп кунагы – Алтын Көз күренми нигәдер. Әйдәгез, бергәләп аны чакырып карыйк.
Көз, көз, алтын Көз,
Без сине бик көтәбез.
Бик моңсу безгә синсез,
Килче тизрәк безгә, Көз!

Матур көй яңгырый. Залга Алтын Көз керә.

**Көз.** Мин Көз Килдем сезгә.
Көзге байлык кулымда.
Муллык белэн байлык телим
Кем очраса юлымда.
**Алып баручы**. Килө шаулы ,алтын матур көзем
Оча яфрак ,исә көзге җил
Тәбигатең бигрәк сокландыргыч!
Хуш киләсен, әйдә кил!
**7 бала**.Көз, көз, көз!
Сине көттек без
Алма,кавын һәм карбызлар
Өлгерми синсез.
**8 бала**.Көз,көз,көз,

Көзсез күңелсез,
Алтын сары яфраклар да
Коелмый синсез.
**9 бала**. Көз килде дә бөтен җирне
Сары төскә буяды
Яшелгә дә буяр иде
Юктыр ахры буявы
**10 бала**.Көз килде. Үләннәр
Саргайды шиңде
Сап-сары яфраклар
Җиргә сибелде
**11 бала**.Кай ара җылы җил
Көньякка йөгерде?
Алмалар өлгерде
Бакчага көз керде.

"Яфраклар" биюе башкарыла.

Көз. Саумы, нәни дусларым!
Сезне сагынып килдем мин,
Сезгә аяз көннәрдә
Яңгырда алып килдем мин.

"Яңгыр" татар халык уен җыры башкарыла

**12бала**. Апа, безгә артыбыздан
Шыбыр-шыбыр кем дәшә?
Алып баручы.Кем дә дәшми, көзге яңгыр
Зонтик белән сөйләшә.
"Зонтиклар" биюе башкарыла.

**13 бала**.Моңлы, гүзәл, матур аяз көннәр,
Мул игеннәр- синең бүләгең
Сокландыргыч синең тәбигатең,
Бигрәк матур ,ай-хай ,күлмәгең.

**14 бала**.Көз көннәре бик күңелле,
Бик күп җимешләр пешә.
Помидор, карбыз өлгерә,
Алмалар өзелеп төшә

**Көз.** Рәхмәт матур сүзегезгә. Хәзер мин сезгә табышмаклар әйтәм ,ә сез җавап бирерсез.
1.Кат-кат тунлы,
Карыш буйлы.
2. Җир астында җиз бүкән.
3.Тәрәзәсе юк, ишеге юк,
Эче тулы халык.
4. Кечкенә сары карт,
Кигән туны тугыз кат.
5. Кечкенә генә йорт,
Эче тулы корт.
6.Үзе шардай,
Эче кандай,
Тәме балдай.

**Көз.**Рәхмәт балалар , бик әйбәт белдегез.Ә менә хәзер «Тәме буенча яшелчәне таны» уены уйнап алыйк.
**Көз.** Бигрәк куп беләсез икән .Менә минемдә сезгә бүләкләрем бар. Тәмле итеп бергәләшеп ашарсыз.
**15 бала**.Ямьле кояш, нурлар чәчеп
Елмаеп карый безгә.
Нинди тәмле күчтәнечләр
Кәз алып килгән безгә.
**16 бала**.Алтын яфраклар очалар,
Безнең башларга тиеп
Саубуллаша кыр казлары
Язын кайтырбыз диеп.
**17 бала**.Җырладык та ,биедек тә,
Шигырьләр дә сөйләдек.
Матур гына уйнап алдык,
Бер дэ читенсенмәдек.
Алып баручы.
Хәзер балалар
Түгәрәккә басабыз,
Әйлән-бәйлән әйләнәбез,
Җырлап күңел ачабыз.

“Әйлән-бәйлән уйныйбыз” җырлы-биюле уены оештырыла
(Л.Батыр-Болгари көе, Р.Батулла сүзләре).

**Алып баручы:**Көз-моңсу чак,ямансу чак,
Көн дә ява яңгырлар.
Тик безнең бакчада һаман
Яңгырый дәртле җырлар!
(”Шат балалар” җыры башкарыла.)
Бәйрәмебез шушың белән тәмам.

# Сау бул, бакча!

**А.б.** Кадерле балалар, хөрмәтле әти-әниләр, килгән кунаклар, балалар бакчасында эшләүчеләр!
Бүген  безнең бакчада зур бәйрәм – бакча белән хушлашу!
Без бакчабыздагы иң акыллы, иң тәртипле кызларны, малайларны мәктәпкә белем алырга озатабыз. Менә сез дә, балалар, мәктәп яшенә кадәр үсеп җиттегез!

Шуклыклары белән безне сагайткан, шат авазлары белән безне сөендергән, бәйрәмнәрдә, эштә безнең зур ярдәмчеләребез булган балалар бүген балалар бакчасына соңгы тапкыр бәйрәмгә җыелдылар! Ә шулай да бүген күңелләребез шат, чөнки балалар барысы да нинди матурлар, таза-саулар!
Ничә ел инде менә
Майның шушы көнендә,
Безнең матур бакчагага
Мәктәптән хәбәр килә.
Безнең бакча балаларын
Укытучы апалары
Беренче сыйныфка дип
Укырга чакыралар!
Бүген менә аларны,
Бергә-бергә, әлбәттә,
Тантаналы рәвештә
Озатабыз мәктәпкә!

**1 Бала.**
Олы бәйрәм бүген бездә
Зурлар инде күбебез,

Бакча белән хушлашабыз –
Бүген соңгы көнебез!

**2 Бала.**
Күңелле дә, күңелсез дә,
Хәлемне белмиләр шул.
Китмәс идем – зур балалар
Бакчага йөрмиләр шул!

**3 Бала.**
Бик елыйсы килә минем,
Инде ни хәл итәсе.
Бакчадан, дуслар яныннан
Бер дә килми китәсе.

**А.б.**
Бик күңелсез булса да,
Ярамый сезгә боегырга,
Бүген бит бездә бәйрәм,
Уйныйк без әйлән-бәйлән.

**4 Бала.**
Парлашып бер басыйк әле
Һәм урталарга чыгыйк,
Якты бакча (залларында) майданында
Ичмасам,биеп алыйк!

**5 Бала.**
Бакча белән хушлашабыз –
7 яшь тулды безгә.
Мәктәпкә белем алырга
Барабыз быел көзгә.

**6 Бала.**
Зур-зур булып үстек инде,
Килгән идек бирегә.
Өйрәнеп кенә килгәндә
Яңа тәпи йөрергә.

**А.б.** - Әйе, балалар, бакчага килгәндә сез бик кечкенә кызлар һәм малайлар идегез. Сезне тәрбияче апаларыгыз:
Битегезне-кулыгызны юарга,
Кулга кашык тотарга,
Көндезләрен йокларга,
Биергә һәм җырларга,

Яттан шигырь сөйләргә өйрәттеләр.

**1 Бала.**
Рәхмәт, сезгә, бик зур рәхмәт,
Тәрбияче апалар!
Бездән сон да шаулап торсын,
Гөрләп торсын бакчалар!

**2 Бала.**
Көйсезләнсәк, еласак та
Сез гел сабыр булдыгыз,
Безнең баштан сыйпап торды
Сезнең йомшак кулыгыз.

**3 Бала.**
Өйрәттегез еламаска,
Өйрәттегез көлергә.
Өйрәттегез тагын бик күп
Төрле-төрле һөнәргә.

**А.б.**
Әйе, балалар!
Балалар бакчасында сез
Дуслар булып яшәдегез
Бик күп нәрсәләр белдегез!
Бик күп җырлар өйрәндегез…
Инде менә үсеп җиттегез,
Сау бул, бакча, – диясез!

**1 Бала.**
Әйе, безне бакча көтә,
Кыңгырулы зур мәктәп.
Ә бу юлга безне бит сез
Чыгардыгыз җитәкләп.
Анда да без сынатмабыз,
Менә күрерсез әле.
Болар – безнең бакчаныкы,
Диеп йөрерсез әле.

**2 Бала.**
Тәрбияче апа елый…
Бу дөнья кызык кына:
Китәсе килми моннан да,
Мәктәп тә кызыктыра.

**3 Бала.**
Гел карап торырмын инде
Шушы бакча ягына…
Нигә укытмыйлар икән
Шушы бакчада гына?!

**А.б.**
Өстәлегез, балалар, һәрвакытта
Тәмле аштан тулы иде.
Рәхмәт пешекче апаларыгызга,
Тамагыгыз һәрчак тук иде.

**1 Бала.**
Кадерле апалар, сез безгә,
Шундый якыннар,
Шуңа күрә дә
Һәр апаны зурлыйбыз,
Һәм зур рәхмәт әйтәбез!

**2 Бала.**
Безне анда мәктәп көтә,
Безне көтә парталар.
Түземсезлек белән көтә,
Укытучы апалар.

**3 Бала.**
Мәктәпкә – белем иленә
Барырбыз без шат,
Серле белем дөньясына
Бүген бирелә старт!

**А.б.** Безнең балалар мәктәпкә барырга бик ныклап әзерләнделәр. Алар инде хәрефләр таныйлар, 100 гә кадәр саный да беләләр. Әйдәгез әле, хәзер аларның үзләрен тыңлап карыйк. Мәктәптә аларны ниләр көтә икән?

**1 Бала.**
Телибез без хәреф танырга,
Алфавитны ятларга
Хәрефкә-хәрефне ялгап,
Сүзләр тезеп язарга.

**2 Бала.**
Бик күп китаплар укырбыз,
Күп нәрсәләр белербез.
Үскәч кирәк һөнәрләрнең

Серен үзләштерербез.

**3 Бала.**
Мәктәптә яхшы укырбыз,
Тәртип бозып йөрмәбез.
Бакчабызның исеменә
Бер тап та төшермәбез.

**4 Бала.**
Хуш булыгыз һәммәгез дә,
Сау булыгыз, апалар!
Кала курчакларыбыз,
Безне көтә парталар.

**А.б.** Кадерле балалар, сез безгә шундый якыннар! Кошлар язын кайта, сез китәсез, хушлашабыз бүген моңаеп, еллар үткәч, тагын бер килерсез әле якын бакчагызны сагынып!

**1 Бала.**
Тәрбияче апалар!
Безнең әниләр күк сез,
Рәхмәтебез сезгә чиксез
Сезне онытмабыз без!

**2 Бала.**
Безнең шушы рәхмәтләрне
Кабул итеп алыгыз.
Безнең күңелләрдә изге
Затлар булып калыгыз!

**А.б.** Кадерле балалар! Без сезне олы юлга – мәктәпкә озатабыз! Сезгә бәхет, шатлык, сәламәтлек, озын гомер, киләчәктә укуыгызда зур уңышлар телибез! Исән-сау булыгыз!
Менә тәмам кичәбез дә,
Моңсу бит ул бакча белән хушлашу,
Вальс биик әле дуслар,
Вальс – ул саубуллашу!

“Куян кызы “ әкияте

***Катнашалар:*** Әни куян, Куян кызы, Тиенкәй, Сорыкай, Төлкебикә, 2 куян баласы, Доктор Айболит.

Куян өе. Әни куян өстәл янында угычтан кишер уа. Куян кызы йөгереп кайтып керә.
- Әнием, мин кайттым.
Әнисе кызын кочаклап ала:
- Шаян кызым син минем,
  Таң йолдызым син минем,
  Йөрәгемдә кабынган
  Шатлык җырым син минем.

  Таңнан торып, урманда
  Син уйныйсың көнозын.
  Аргансыңдыр, кил, кызым,
  Утыр, ял ит, йолдызым!
Куян кызын сәкегә утырта.
- Бәбкәм, кыш килде, кар суык, аякларың туңмасын, сызламасын, менә сиңа өр – яңа киез итекләр алып кайттым, - дип Әни куян итекләр алып килеп бирә. – Яле, кызым, киеп кара әле.
Куян кызы итекләрне кия, сикереп торып:
- Рәхмәт, әнием!, - дип әнисен кочаклап, үбеп ала.
Әни куян эшләрем бар дип, чыгып китә. Куян кызы җырлый:
- Аягымда киез итек
  Әй биим мин, биим мин.
  Миннән дә оста биюче

Юктыр диеп уйлыйм мин.
Учларыңны шапылдатып,
Колакларны селкет тә,
Тыпыр – тыпыр, тыпыр – тыпыр.
Тыпыр – тыпыр, тыпырда.
Әй, матур минем итекләр,
Әй уйныйм мин, уйныйм мин.
Матур итекләрем киеп
Бер тыпырдап биим мин.

Шулвакыт тыштан Тиенкәй тавышы ишетелә:

- Куянкай, әйдә безнең белән уйнарга.

Куян кызы:

- Туйдым мин бу итекләрдән, алар белән йөрү бик җайсыз, әнием тапма-сын әле, - дип итекләрне яшереп куя.

- Әнә ничек рәхәт, җиңел, - ди һәм йөгереп уйнарга чыгып китә.

Урман аланы. Җәнлекләр түгәрәккә басалар. Төлке баласы:

- Әйдәгез, уйнап алабыз. Әйдә, Тиенкәй, уртага кер.

Җырлы – уен:

Син уртада, без тирәндә
Әйләнәбез, Тиенкәй.
Син нишләсәң, ни кылансаң
Без кыланырбыз шулай.

Тиен аякларын күрсәтеп бии, Сорыкай чүгәли, Куян кызы сикерә. Шулвакыт Куян кызы елап җибәрә.

Җәнлекләр җырлыйлар:

Куян кызы, ни булды?
Күңелләрең ник тулды?
Ай – яй – яй, ай – яй – яй
Күңелләрең ник тулды?

**Куян кызы:**

Аякларым авырта
Уйный алмыйм мин шуңа.
Ай – яй – яй, ай – яй – яй
Уйный алмыйм мин шуңа.
Ай – яй – яй, ай – яй – яй
Уйный алмый ул шуңа.

**Бүре баласы:**

- Әйдә, Куянкай, без сине әниең янына илтеп куябыз.
Бүре баласы белән Тиенкәй  Куян кызын җитәкләп Әни Куян янына китәләр.
**Куян кызы икенче куян кызына һәм Төлкебикәгә:**
- Әйдәгез, без өйгә кайтыйк, әниләребез көтәдер. (Чыгып китәләр.)
Тиенкәй белән Сорыкай Куян кызын җитәкләп Әни куян янына  киләләр.
**Әни куян:**
-Ни булды?
**Куян кызы:**
Аягым авырта.
**Әни куян:**
-Кызым, кызым, якты йолдызым, синең аягың шешкән ич, - ди. Кая алып барырга, ничек дәваларга?
**Тиен:**
**-**Кайгырма, Куянкай, кызыңның аягын бик тиз төзәтеп була. Моның өчен “Доктор Айболит”ка барырга, аңардан киңәш сорарга кирәк, - дигән. Әйдә, юлны үзем күрсәтәм.
Чыгып китәләр. Айболит янына баралар. Ул бу вакытт Зур төлкене дәвалый.
**Тиенкәй:** Менә Доктор Айболит монда яши инде.Ә миңа кайтырга кирәк, - дип чыгып китә.
**Әни куян:**
-Керергә ярыймы?
**Доктор Айболит:**
Әйдәгез, әйдә, керегез. Мин балаларны чиратсыз карыйм. (Төлке саубуллашып чыгып китә.) Ни булды?
**Әни куян:**
-Менә Куянкаем, йомшаккаем, мин алган итекләрне кимичә, карда яланаяк йөргән. Аягы шешкән, авырта.
**Доктор Айболит:**
**-**Яле, Куянкай, утыр әле менә монда. Хәзер без синең аягына дарулар сөртербез.(Дару сөртә.) Аягың төзәлгәч, киез итекләреңне инде салкын көннәрдә бер дә салма, әниеңнең сүзен тыңла, тагын начар хәлгә калма.
**Куян кызы:**
-Рәхмәт сиңа, Доктор Айболит, моннан соң мин итекләремне бер дә салмамын.
**Әни Куян:**
-Рәхмәт сиңа, Доктор Айболит. Сау бул. Китәләр.

Урман аланы.
**Әни куян.**
-Я, кызым, аягың ничек, авыртмыймы?

**Куян кызы:**
-Әни, минем аякларым авыртмый. Иптәшләрем янына уйнарга чыксам ярыймы?
**Әни куян:**
-Ярый, йомшагым. Тик онытма! Итекләреңне инде бер дә салма!
**Куян кызы:**
-Дусларым, килегез әйдәгез уйнарга. (Барлык җәнлекләр чыгып баса.) Әйдәгез, бер биеп алыйк. (Җәнлекләр биюе.)

Тәмам

# “Хуш киләсең Нәүрүз”

***Балалар.***
Ач ишегең, керәбез,
Нәүрүз әйтеп киләбез!

***Балалар.***
Өйдәме, түтәй?

***Өйдән өй тәрәзәсеннән карап:***
Өйдә, өйдә,
Килегез, кил, балакайларым,
Мин сезне күптән көтәм,
Нәүрүз котлы булсын!

***Балалар.***
Түтәй!
Тизрәк бир күкәй!
Бирсәң безгә өч күкәй,
Тавыгың салыр йөз күкәй!

Табакка кабак кирәк,
Май, күкәй, калач кирәк,
Күмәчен дә кызганма,
Озак яшә сызланма.

***Түтәй.***
Менә, балалар, алыгыз,
Кәрҗинегезгә салыгыз.

Барыгызны да бәйрәм белән котлыйм. Сәламәтлек, шатлык, бәхет телим. Нәүрүз котлы булсын!

***Балалар.***
Нәүрүз котлы булсын!
Нәүрүз котлы булсын!

***Радель.***
Кыш китте, яз килде,
Үрдәк белән каз килде.
Былбылдан аваз килде —
Нәүрүз мөбарәк булсын!

***Аделина.***
Түтәй эшең уң булсын,
Теләгәнең юш булсын,
Күңелләрең хуш булсын —
Нәүрүз мөбарәк булсын!

***Динә.***
Нәүрүз хакы биш алтын,
Бирсәң ярар ике алтын,
Карама ялтын-йолтын —
Нәүрүз мөбарәк булсын!

***Дарина.***
Казанга бармак кирәк,
Балыкка кармак кирәк,
Ә безгә бәйрәм кирәк,
Нәүрүз мөбарәкбад!

***Галимов Искәндәр.***
Нәүрүз әйттек без сезгә,
Хакын бирегез безгә,
Яшегез җитсен йөзгә,
Малыгыз артсын көзгә,
Нәүрүз мөбарәкбад!

***Бергә.***
Нәүрүз мөбарәкбад!

*(Түтәй күчтәнәчләрен балаларга тапшырып керeп китә).*

***Алып баручы***. Нәүрүз — Яңа ел, яңа көн дигәнне аңлата. Ул — көн белән төн тигезләшкән вакыт. Менә шуннан соң көн озыная башлый. Ә Нәүрүз бәйрәме нинди бәйрәм?

***Балалар.***
— Яңа ел бәйрәме!
— Яз бәйрәме!
— Кышны озату, язны каршылау бәйрәме!
— Дуслык бәйрәме!

**«Яз килә» җыры** ***Музыка № 1***

Җир җылы һәм иркә,
Кояш та елмая.
Бар дөнья уяна,
Бар дөнья уяна.
    Яз килә, яз килә
    Чәчәкләр уяна.
    Йөрәккә яз килде
    Бар дөнья куана.

Канатлы җырчылар
Моңлана талларда.
Бар дөнья уяна,
Бар дөнья уяна.
    Яз килә, яз килә
    Чәчәкләр уяна.
    Йөрәккә яз килде
    Бар дөнья куана.

(Бүлмәгә карга очып керә.)

**Алып баручы**. Балалар, карагыз әле, Кара карга килгән, ул — яз киләсен хәбәр итүче.

***Кара карга.***
Исәнмесез, балалар!

***Балалар.***

Исәнме, Кара карга!

***Алып баручы.***
Карга, кая таба очасың?

***Кара карга.***
Ачылды ак калын юрган,
Исә язгы җилләр дә,
Без кайтабыз сагындырган
Туган, үскән җирләргә.
Көннәрне юлда үткәреп.
Куанышып сезгә очтык,
Канатларга күтәреп,
Сезгә яз алып кайттык.
Яз кызы Нәүрүзбикә тиздән сезгә килеп җитә! (Карга «очып» чыгып китә.)

***Адель.***
Көннәр аяз, күктән алсу
Нур сибеп кояш көлә.
Җиргә тама көмеш тамчы,
Сагынып көткән яз килә!

***Данил.***
Әйтегезче, кайсы вакыт
Яздагыдан ямьлерәк?
Кыш айларын да яратам,
Әмма яз күңеллерәк!

*Нәүрүзбикә керә.* ***Музыка №2***

***Нәүрүз.***
Исәнмесез, балалар!

***Балалар.***
Исәнме, Нәүрүзбикә!

***Нәүрүзбикә.***
Бик күп сулар үттем мин,
Агымсулар кичтем мин,
Сезгә килеп җиттем мин,
Нәүрүз әйтеп үттем мин.
Нәүрүз мөбарәк булсын!

***Айваз.***

Нәүрүз килде, тиз килде,
Нәүрүз килде, яз килде,
Яз белән байлык килде,
Яз белән шатлык килде.

***<u>«Нәүрүз килә» җыры башкарыла.</u>***

Нәүрүз килә, Нәүрүз килә,
Нәүрүзне зурлыйк әле.
Гөрләвекләр челтерәвенә
Кушылып җырлыйк әле.
Яз килгәндә
Уяналар сөмбелләр.
Безнең өчен генә
Үсәр ал гөлләр.

Нәүрүз килә, Нәүрүз килә,
Илләр, көннәр ямьләнә.
Бергәләшеп биергә дип,
Куллар кулга бәйләнә.

Нәүрүз килә, Нәүрүз килә,
Күктән нурлар сибелә.
Туган илем, туган җирем
Язны күреп сөенә.

***Нәүрүз.***
Котлап сәлам бирдегез,
Мине көтеп алдыгыз,
Имин йортта торыгыз,
Кәеф-сафа корыгыз.
Инде мине тыңлагыз,
Моңаеп утырмагыз —
Уйнагыз да көлегез,
Биегез дә җырлагыз —
Нәүрүз мөбарәкбад!

***Алып баручы.***
Әй, дуслар, килегез,
Күңел ачу көнебез.
Татарча матур итеп
Без биибез, күрегез!

(«Там, там » биюе башкарыла.)

Там, там, тамчы там,
Тамганыңны яратам. *2 тапкыр*
Тамган тамчыларга карап,
Мин җырларга яратам. *2 тапкыр*

Тамчы тама, тамчы тама,
Тамчы тама түгелме? *2 тапкыр*
Тамчы тамса, матур язлар
Килеп җитә түгелме? *2 тапкыр*

Там, там, тамчы там,
Тамганыңны яратам. *2 тапкыр*
Тамган тамчыларга карап,
Мин җырларга яратам. *2 тапкыр*

***Алып баручы***.
Яз иртәсен котлагандай матур булып,
Зәңгәр күкне каплап алды зәңгәр болыт.
Бизәкләгән төсле булды бөтен һава,
Кар өстенә шыбыр-шыбыр ләйсән ява!

**«Ләйсән ява» җыры.** ***Музыка № 3***

Яз иртәсен котлагандай матур булып,
Зәңгәр күкне каплап алды аксыл болыт.
Бизәкләгән төсле булды бөтен һава,
Кар өстенә шыбыр-шыбыр ләйсән ява!

Җир өстендә яткан карлар эреп бетсен,
Басуларда эш кайнасы көннәр җитсен.
Бер чыгарбыз бакчаларга ул көннәрдә
Яшелчәләр утыртырбыз түтәлләргә.

***Нәүрүз.***
Яратыгыз көзне дә, яратыгыз кышны да,
Яратыгыз җәйне дә, яратыгыз язны да.

***Балалар.***
Нәүрүз, Нәүрүз, зур рәхмәт!
Нәүрүз, Нәүрүз, зур рәхмәт!

***Музыка №4*** (Кыңгырау тавышы ишетелә.)

***Алып баручы***. Балалар, ишеттегезме, кыңгырау тавышы. Безгә кунаклар килә, ахрысы.
(Кыш бабай керә.)

***Балалар.*** Исәнме, Кыш бабай!

***Кыш бабай*** (Нәүрүзгә).
Бу нинди бәйрәм монда?
Миңа әйтми киткәнсең,
Бер өрсәм, җил исәр,
Ике өрсәм — кар явар,
Кит, Нәүрүз, кит!

***Нәүрүз.***
Шып итсәм — җил туктар,
Елмайсам — карың елар,
Үзең кит, Кыш бабай!

***Кыш бабай.***
Минем җитез атларым бар,
Гыйнвар, февраль айларым бар.

***Нәүрүз.***
Минем дә бит атларым бар,
Җылы апрель, майларым бар.

***Кыш бабай.***
Әйдә, алайса ярышыйк,
Кем җиңә, шул кала.

***Алып баручы***. Кыш бабай, Нәүрүзбикә, балалар бит икегезне дә яраталар.

***Кыш бабай.*** Рәхмәт, рәхмәт. Менә хәзер карыйк әле ярышып.
Менә кашык, менә күкәй,
Тот кулыңа, чибәркәй.
Син дә йөгер, мин дә калмам,
Кайсыбыз килер алдан?

***Музыка № 5***
(Нәүрүз, Кыш бабай кашыкка күкәй салып йөгерәләр.)

***Нәүрүзбикә***.
Инде хәзер биеп алабыз.

***Музыка № 6***
(Кыш бабай бии-бии дә егыла.)

***Кыш бабай.***
Уф, арыдым, су кирәк,
Җиңелдем бит, җиңелдем.
Эредем бит, эредем,
Яз хуҗа булды инде!
Сезнең белән Нәүрүз кала,
Ә мин киттем, хушыгыз.

(Саубуллашып китә.)

***Музыка № 7*** (Күңелле көй ишетелә. Хуҗа Насретдин керә.)

***Хуҗа Насретдин.***
Хуҗа Насретдин товары
Һәркемгә дә җитәрлек.
Тары-бары, растабары
Һәркөн сатыла товары.
Яшьләр өчен шатлык мин дә,
Картларга да тансык мин.
Халык үлмәс, мин үлмәсәм.
Мәңге яшә, Насретдин!

***Алып баручы***. Әссәламегаләйкем, Хуҗа Насретдин!

***Хуҗа Насретдин***. Вәгаләйкем әссәлам! Исәнмесез, балалар! Бу базармы?

***Алып баручы***. Юк, бу базар түгел, бу бит балалар бакчасы.

***Хуҗа Насретдин***. Яхшы, яхшы, миңа балалар бакчасы да ярый, бераз ял итеп алырмын.

***Алып баручы***. Хуҗа Насретдин! Бүген бездә «Нәүрүз» бәйрәме. Ә сез безнең олы кунагыбыз булырсыз. Сез бит бик күп мәзәк, мәкаль, табышмак, такмаклар беләсез. Безгә дә сөйләмәссез микән?

***Хуҗа Насретдин***. Була ул, тыңлагыз! Мин мәкальне башлармын, сез тәмамларсыз. Тырышкан табар … (ташка кадак кагар.) Кем эшләми, … (шул ашамый.) Ялкау утырып йоклый, … (ятып ашый.) Ни чәчсәң, ...(шуны урырсың).

***Хуҗа Насретдин.***
Бүген «Нәүрүз» бәйрәме,
Күңел ачу көнебез.
Тәмле прәннекләр алырга
Минем янга килегез.
Товарымны сатмыйм әле,
Сезне сыйлыйсым килә.
«Нәүрүз» бәйрәмен котлап,
Бүләк бирәсем килә.
Сый-хөрмәтләр сезгә булсын,
Нәүрүз мөбарәк булсын!

***Балалар.***
Рәхмәт сезгә, Насретдин!

***Хуҗа Насретдин.***
Миңа китәргә кирәк,
Сау булыгыз, балалар! (Китә)

***Вильдан***.
Җырларыбыз юлдаш булсын,
Юлдаш булсын, яңгырап торсын.
Эшләрегез уңнан булсын,
Илебезне бизәп торсын!

**Җыр «Язгы тамчы».** ***<u>Музыка № 8</u>***

Тып-тып тып, тып-тып, тып-тып, тып
Тамчы тама талларга,
Талларымнын борелэре
Куаныша шунарга, куаныша шунарга.

Тып-тып тып, тып-тып, тып-тып, тып
Яз тама тамчы булып
Кояш нурлары биешэ,
Шул тамчыга куанып, шул тамчыга куанып.

***Тәрбияче.***
Балалар, нишләптер көн караңгыланып китте, әйдәгез кояшны чакырыйк әле.

***Балалар.***
Кояш, чык, чык, чык,

Тәти кашык базарда,
Ботка пешәр казанда.
Батыр карны елак ит,
Җылың белән кунак ит.

(Кояш чыга.)

***Роберт*.**
Кояш, кояш, син биектә
Бар дөньяны күрәсең.
Әйтче, иң матур җир кайда?
Син бит инде беләсең?!

***Кояш.***
Әйе, беләм, мин әйтәм, тыңлап кара:
Иң матур җир — Туган җир ул,
Онытма моны, бала!

**"Кояшлы ил" җыры.** ***Музыка № 10***

Кояшлы ил – безнең ил,
Күге аның гел аяз.
Кыш китерсә кыш бабай,
Чәчәк алып килә яз.

Һавасы да җире дә,
Салават күпере дә,
Яңгыры да, кары да –
Безгә якын бары да.

Сандугачлы урманы,
Ашлык тулы кырлары,
Бөтен җиргә яңгырый
Безнең бәхет җырлары.

***Алып баручы:***
Еллар имин, илнең куге аяз булсын
Сабыйларның шат авазы янгырап торсын.
Бәйрәм мөбәрәк , табыннар түгәрәк булсын
Хәерле юллар, хәерле еллар насыйп булсын!

***Нәүрүзбикә:*** Минем дә китәр вакытым җитте. Сау булыгыз балалар, киләсе очрашканнарга кадәр!

***Балалар:*** Сау бул, Нәүрүзбикә!

**“Юлда йөрсәң-бул өлгер,**

**Юл йөрү кагыйдәсен син бел!”**

## Максат:

- Юл йөрү кагыйдәләрен, юл билгеләре, турындагы белемнәрен тикшерү һәм ныгыту;
- Балаларның урамда һәм юлда хәвефсез йөрүне күз алдына китерүләрен формалаштыру;
- Балалар юл транспорт травматизмын кисәтү максатыннан, балаларның юлда үзеңнең тотуның төп кагыйдәләрен үтәү күнекмәләрен һәм юлда үзеңне тоту культураларын үстерү.

Карлсон юлга, машина каршысына килеп төшә. Полиция вәкиле свисток сызгыртып килә( Карлсон як-якка карана)

**Полиция.**

Карлсон, гафу итегез,

Штраф түләп китегез.

Юлга килеп төштегез,

Кагыйдәне боздыгыз!

Күктә очкан бу Карлсон

Җир өстенә ник төшкән?

Юлдан машина йөри

Моны бүген кем белми?

**Карлсон**.

Кайда соң ул юл дигәне?

Күктә юллар юк бит ул.

Очкычым ватылганганга

Җиргә егылып төштем мин.

**Полиция.**

Җирдә тыныч йөрү өчен юл кагыйдәләрен белергә кирәк.

**Карлсон**.

Ә нәрсә соң ул юл кагыйдәләре? Алар тәмлеме?

**Полиция**.

Юк,Карлсон, аларны ашап булмый. Аларны өйрәнергә кирәк.

**Карлсон**.

Кагыйдәләрне дә белмим,

Очкычым да ватылды.

Миңа нишләргә инде?( елый)

**Полиция**.

Озын юллар бик серле

Сез күрмәгән юллар гел алда.

Еракка барыр өчен

Юл билгеләрен кирәк белергә.

Берәү, икәү өчәү дүртәү.

Билгеләр бик күп төрле!

Истә калдырыр өчен

Мәктәпкә барыйк әле.( Китәләр)

**Аю**.( велосипедка атланып керә).

Педальләрне әйләндереп,

Ике тәгәрмәчтә чабам,

Рульне тотам, алга барам-

Билгеләрне күреп  алам.

Билгеләре күп икән,

Миңа кайсысы икән?!

Зинһар ярдәм итегез,

Юл йөрү кагыйдәләрен

Өйрәтә торган мәктәп

Кайда икән әйтегез!

**Полиция.**

Аю дус, исәнме! Нишләп соңга калдыгыз? Дәрес башлана бит инде.

**Аю.**

Әллә ничаклы машина...

Урыссу урамында.

Тимер юлдан чыгалмыйча

Аптырап йөрдем шунда.

**Полиция**.

Юл кагыйдәләрен һәрчак

Кирәк истә тотарга.

Юлны аркылы чыкканда

Кара уңга һәм сулга.

Күрсәң алдында машина

Ашыгып басма юлга.

Моны һәрчак белү өчен

Әйдә, безнең мәктәпкә.

Автошкола дигән афиша тора. Парта артында Карлсон утыра.

**Аю.**

Хәерле көн Карлсон. Син монда нишләп утырасың?

**Карлсон.**

Очкычым ватылды да, түбәдән егылып төштем...

Юл йөрү кагыйдәләрен

Истә калдырыр өчен

Менә шушы абый мине

Алып килде мәктәпкә.

Куян(елап керә)

Аю.  Ни булды куянкай, нигә елыйсың?

Куян. Дәрескә соңга калмыйм дип

Юлны йөгереп чыкканда,

Әллә нинди зур машина

Минем өстемә килде,

Аягым кысылды, йөрәгем алынды.

Полиция . Ярый әле исән калгансың Куянкай. Юлны һичбер вакыт йөгереп үтәргә ярамый. -Башта сулга, аннан уңга карарга, шуннан соң гына юлдан чыгарга кирәк.

Полиция. Игътибар, дуслар!

Юл йөрү кагыйдәләрен

Өйрәник әле тизрәк!

Яле, Компьютерым

Күрсәт әле юл билгеләрен:

( Экранда юл билгеләре ачыла)

1.Урыссу буйлап йөргәндә
Йөр син җәяүле сукмагыннан

2. Урамны аркылы чык син
Тик җәяүле сукмагыннан.

3.Дуслар, мин сезгә бүген
Яңа билге алып килдем.
Бик ошаса билгебез
Урамнарда күрербез.

**Карлсон**. Кара , Аю дус, бу нинди өч күз ул?

**Аю**. Белмим, шул. Яшел күзе гел безгә карап тора, әйеме?

**Полиция**. Монысы- светофор.

**Карлсон**. Ә нәрсә соң ул Светофор? Аны ашап буламы?

**Полиция**
Светофорның сигналы бар
Тыңла аны карусыз.
Кызыл төс-әле куркыныч,
Тукта син, дигән сүз.
Сары әйтә: "Әзерлән",-ди-
Хәзер юл ачылачак.
Яшел әйтә: "Әйдә" кузгал.
Юлдан чык курыкмыйча!"
Светофорга кара син,
Тора ул сакта.
Чыгарга кирәк юл аша
Яшел ут янган чакта.
Менә шуны Карлсон, Аю
Истә тотыгыз, һәрчакта.

**Җыр "Светофор"**

Урамны чыккан чакта
Башта карагыз чатка.
Анда тора зур фонарь
Светофор диләр аңар.
Һаман уяу була ул,
Аннан гына сора юл.
Күзләре өчәү аның,
Шулар белән сөйләшә.
Кызыл ут-чыгу юк,
Сары ут-сабыр ит,
Яшел ут-юл ачык, әйдә чык!

**Полиция.**
Юл йөрү кагыйдәләрен
Төгәл үтәп йөрсәгез,

Юл чатында басып торган Светофорны күрсәгез,
Шул чагында бәла-каза
Сезне читләтеп үтәр
Кара кайгы, күз яшьләре
Сездән мәңгегә китәр.

**Бергә.**
Сәламәт булып каласың килсә-
Юлда ярамый уйнарга.
Ярамый шуарга!

**Карлсон**.
Рәхмәт сезгә дусларым! Мин боларны истә тотармын. Хәзер инде мин урада да дөрес итеп йөрермен. Сау булыгыз.
**Аю.**
Ә мин хәзер Казан  урамнарында да йөри алачакмын. Ура!! Рәхмәт полиция абый!
Куян. Мин  дә юл аша чыкканда һөрчак кагыйдәләрне үтәрмен. Сау булыгыз дуслар.
**Полиция.**
Урамда һәрчак сез сак булыгыз,
Юл билгеләрен истә тотыгыз!
Бәла-казадан сакланыйм дисәң,
Кагыйдәләрне һич онытмагыз!

## “Юлда да акыл кирәк”

**Максат:** Кече яшьтәге балаларга  юл йөрү кагыйдәләрен төшендерү, аларны төгәл үтәргә күнектерү; бакча белән гаилә арасындагы бәйләнешне ныгыту.

**Алып баручы:** Игътибар, игътибар! КВН кичәбезне башлыйбыз. Ике команда ярыша. (Ата-аналар һәм балалар бергә)

“ЯШЕЛ УТ” һәм “КЫЗЫЛ УТ”. Әйдәгез, аларны каршы алыйк. (Музыка астында командалар керә.

**Алып баручы.** Без яшәгән шәһәрне
Китапка кертеп була.
Урман, юл әлифбасын
Шәһәр безгә әйтеп тора.

Әнә ул – баш өстендә,
Хәсрәт булмасын дисәң –
Юл әлифбасын онытма.

**“ЯШЕЛ УТ” командасы капитаны:**
Кызыл ут командасына
Кайнар сәлам юллыйбыз.
Чын күңелдән дөрес итеп
Җавап бирүләрен телибез.

**“КЫЗЫЛ УТ” командасы капитаны:**
Без бүген бу кичәдә
Көч сынашырга килдек.
Биербез, күңел ачарбыз
Без дә артка калмабыз.

**Барысы бергә:** Юл кагыйдәләрен бозмаска,
Беркайчан да онытмаска
Сүз бирәбез!

**Алып баручы:** Ә хәзер мин сезнең белемнәрегезне тикшереп карыйм, сораулар бирәм. Ә сез җавап табыгыз, әгәр җавапны дөрес дип санасагыз, бергәләп әйтегез: “Бу бит мин, бу бит мин. Минем якын дустым”. Әгәр ялгыш булса дәшмәгез.

1. Кем шулай алга чаба
   Светофорны күрмичә.
2. Кем белә яшел төснең
- Юл ачык дип әйткәнен.
  Ә сарының һәр вакытта
- Тукта сабыр! – дигәнен.
3. Кем белә кызыл төснең
- Кузгалма, тор! – дигәнен.
4. Кайсыгыз трамвайда
   Өлкәннәргә урын бирә?

*(Өч бала – светофорның 3 төсе керәләр).*

**Алып баручы:** Светофор булса
Урам чатында
Игътибар белән
Син аңа кара.

**Сары төс:** Иътибарлы бул –
Урамда әле
Ачык түгел юл!

**Кызыл төс:** Янса кызыл төс
Тукта шунда ук.
Алга барырга
Димәк, һич юл юк.

**Алып баручы:** Бергә булса да
Ялгыз булса да,

Урамда дөрес
Йөрсен һәр бала!

**Алып баручы:** Болар нәрсә балалар?
**Балалар:** Светофорның өч төсе.
**Алып баручы:** Әйе, алар сезне биергә чакыралар.
Әгәр яшел ут янса күңелле итеп биегез,
Сары янса – чүгәләгез, кызыл янса – туктагыз, -
Бер берегезгә бармак янагыз:
“Алга барырга ярамый”.
**Алып баручы:** Урамнарны күзәтеп,
Ваемсызны кисәтеп,
Чатта тора светофор.
Сакта тора светофор.
*(Кызыл төс алга чыга).*
**Балалар:** Тукта!
**Алып баручы:** Сары.
**Балалар:** Көтеп тор!
**Алып баручы:** Яшел.
**Балалар:** Бар!
*(Светофорның төсләре урыннарына утыралар. Музыка яңгырый, Белмәмеш керә, бер кулы бәйләнгән, исәнләшә).*
**Алып баручы:** Белмәмеш, сиңа ни булды?
**Белмәмеш:** Балалар, урамнарга, юлларга нindидер билгеләр куелган. Алар нәрсә өчен икән?
**Балалар:** Урамда авария булмасын, кешеләр бәхетсезлеккә юлыкмасын өчен!
**Алып баручы:** Алайса сез, балалар, Белмәмешкә бу билгеләрнең мәгънәләрен аңлатыйк инде. Яшел утлылар, урам аша чыкканда куела торган билгеләрне күрсәтегез әле. “КЫЗЫЛ УТ” командасына тимер юл аша чыкканда куела торган билгеләрне алып килергә куша. Жюри йомгак ясый.
**Алып баручы**: Хәзер ике команда арасында эстафета. “Кем машинаны тизрәк китереп җиткерә?”
(Ярыш. Нокталарны тоташтырып рәсемне ясап бетерергә).
**Алып баручы:** Викторина “Нәрсә? Кайда? Кайчан?”
Сораулар:

- Светофорның ничә төсе бар?
- Алар нинди төсләр?
- Светофор кемгә команда бирә?
- Һәр урамның уртасына җиткәч, сары ут янса нишләргә?
- Кызыл утка нишләргә?
- Ә яшелгә?

**Алып баручы:** Ике команда шигырь сөйли. (“Бүләк”, “Кызыл ут” Г. Бәширов сүзләре)
**Белмәмеш:** Балалар, сез бигрәк күп беләсез икән, минем сезне тапкырлыкка да сынап карыйсы килә. (Табышмак әйтә)

1. Барам, барам – очы юк. (Юл)
2. “На” – дисәң, туктамый.
   Печән салсаң ашамый
   Койрыгын борсаң,
   Кычкыра-кычкыра чаба. (Автомобиль)
3. Тәрәзәле һәр ягы
   Җиргә тими аягы
   Сыртында бар дугасы. (Трамвай)
4. Кыяга асылына,
   Тимергә таяна,
   Утырып чаба
   Теләсә кая. (Трамвай)
5. Уф-пуф сулар,
   Уфтанса да алып китәр,
   Барыр җиренә илтәр. (Поезд)
6. Аяклары түгәрәк,
   Куышалар тәгәрәп.
   Үзем утырам, үзем чабам
   Теләсә кая табан. (Велосипед)

**Белмәмеш:** Сез тапкыр балалар икәнсез. Миңа юлларга куела торган билгеләрне күрсәтеп аңлатыгыз. Мин аларны бик шатланып өйрәнер идем.
**Алып баручы.** Ягез әле, сез нинди билгеләрне беләсез, күрсәтегез әле?
(Ике командадан да берәр бала билгеләрне ала, аңлата)
Белмәмеш: Инде миңа китәргә кирәк. Сездә мин күп нәрсәләргә өйрәндем, рәхмәт сезгә. Мине дусларым көтәдер, аларга да өйрәтим әле. Моннан соң беркайчан да юл йөрү кагыйдәләрен бозмам. Юлда йөрер өчен дә акыл кирәк икән. Сау булыгыз.
Белмәмеш китә. Жюри йомгак ясый)
Алып баручы. Безнең әти-әниләр көн дә урам аша йөриләр. Алар нинди билгеләр белән таныш соң?
( Капитаннар ярышы. Ике рәсем эленә, бәхетсезлек очрагы килеп чыкмасын өчен ничек итеп юлны чыгарга икәнлеге аңлатыла)
**Алып баручы.** Күрдегезме, балалар? Безнең халык дөрес әйтә “Юлда йөрер өчен дә акыл кирәк”. Чыннан да шулай икән.
(Жюри йомгак ясый).

## “Теремкәйдә кунакта”

**Максат:** урамнарда һәм юлларда үзеңне хәвефсез тоту буенча белемнәрне һәм күнекмәләрне камилләштерергә, юл билгеләре турында белемнәр формалаштырырга.

1 күренеш.

*Күңелсез генә тычкан керә.*

**Тычкан.** Бүген минем туган көн
Миңа 5 яшь тулган көн.
Бәйрәм итә торган көн.
Ә дусларны чакырырга
Булсын иде “Теремкәй”.
Пирожкилар пешереп
Эчәр идек тәмле чәй.
*(Өйне күрә,әйләнеп йөри).*
**Тычкан** (ишек шакый). Терем-терем-теремкәй,
Теремкәйдә кем яши?
*(Як-ягына карана)*
Берәү дә юк.
Кара, нинди матур өй –
Теләсәң дусларны җый!
Шалтыратып алыйм әле үзләренә, телефон кая икән монда? (“*Телефон” билгесен күрә).* Менә “Телефон” билгесе. *(Телефоннан сөйләшә).*
Минем адрес: Теремкәй, Совет урамы, 25 йорт. “Больница” билгесен тапсагыз. Көтәм сезне!
Теремкәйне җыештырыйм,
Кунакларга бәлеш җитештерим. *(Өйгә кереп китә).*

*Юлга сикереп Әтәч керә.*
**Әтәч.** Кара, миңа сикереп уйнарга нинди сызыклар сызып куйганнар. Әле Тычканга барырга иртәрәк, сикерим рәхәтләнеп.
Кикрикүк, кикрикүк
Сикерик тә сикерик.
Туган көнгә барганчы
Рәхәтләнеп сикерик.
*(Машина кычкырткан тавыш.)*
**Куян** (йөгереп кереп, юлдан тартып ала). Машинага таптала яздың ич, ник юлда сикерәсең?
**Әтәч.** Менә сикерергә матур сызыклар сызганнар ич.
**Куян.** Бу “Җәяүле сукмагы” – зебра дип атала. Әнә аның билгесе. Аның аша юлны гына чыгалар. Ә юлда уйнарга һич ярамый, миңа әнием әйтте.
**Әтәч.** Ярый, алайса, башка җирдә сикерермен. (Китә).

*Куян юлны чыгарга килә.. Каршысына машинада Төлке очрый.*
**Төлке.** Куянкай, куянкай, кая болай ашыгасың?
**Куян.** Тычкан Чи-чи туган көненә чакырды, шуңа ашыгам.
**Төлке.** Ә кайда яши ул Чи-чи?
**Куян.** Яңа гына шалтыратты, Совет урамы, 25 йортта Теремкәйдә яши.
**Төлке.** Әйдә, үзем илтеп куям.

**Куян.** Юк, юк, әни таныш түгел кешеләргә утырма диде.
**Төлке.** Ярый, ярый, ләкин син дөрес юлдан бармыйсың. Менә бу юлны кисеп чык та, урам буенча туп-туры бар. Шунда Теремкәйне табарсың.
**Куян.** Рәхмәт, Төлке апакай. *(Төлке китә).*
**Куян** *( юлны чыгарга килә).* Йөгерим тизрәк, соңга кала күрмим. Бу Төлке апакай дөрес әйттеме икән? *(Каршына милиция чыга).*
**Полиция.**
Туктагыз, гражданин Озынколак.
Кагыйдәне бозмагыз
Машина юлын бары тик
“Зебра” дан үтегез.
Юлдагы бәла-казаларны
Берүк урап үтегез.
**Куян.** Йөгерәм, йөгерәм, ашыгам
Тизрәк бәлеш ашарга.
**Полиция.** Әллә син юл кагыйдәләрен бер дә белмисең, инде, Куянкай?
**Куян.** Зебраны беләм, әни әйтте. Ә кагыйдәләрне белмим.
**Полиция.** Зебраны гына түгел, юл йөрү кагыйдәләрен бөтен кеше дә белергә тиеш. Әйдә мин сине юл аша чыгарам. (Озата).

“*Остановка автобуса” билгесе янында Бүре тора. Төлке килеп туктый.*
**Бүре.** Автобус юк
Вәт кайгы.
Туган көнгә соңарам,
Тычканны котлый алмам.
**Төлке** (килә). Әй, Сорыкай, син кая?
**Бүре.** Кунакка соңга калам.
**Төлке.** Әйдә, утыр, тизрәк.
**Бүре.** Җилдерик җитезрәк.
**Төлке** (машинасы сүнә). Мотор сүнде. Ярдәм ит.
Машинаны арттан эт. (Бүре этеп бара).
**Төлке.** Бу “больница” билгесеме?
Ә Теремкәй күренәме?
**Бүре** (арыган, тирен сөртә).
Моннан йөгереп үт дигән
Күрәсеңме билгене?
(“Осторожно дети” билгесе).
**Светофор** (чыга). Туктагыз, ашыкмагыз!
Кызыл утка чыкмагыз!
Сары утта көтегез.
Яшел булгач, китегез!
**Бүре.** Бу кем соң ул?
Өй-рә-тә.
**Төлке.** Светофор – бу.
Хәрәкәтне көйләтә.

(Светофорга билгене күрсәтә).
**Бүре.** Монда йөгереп йөрергә күрсәткән.
**Светофор.** Юк, юк, дустым, бу билге
Ашыкмаска өйрәтә.
Юлда балалар булыр дип
Шоферларны кисәтә.
**Бүре, Төлке.** Ярый, ярый, аңладык. (Китәләр).
*Велосипедта Аю килә.*
**Аю.** Менә нинди тигез юл
Йөгерәмен "сәпид"тә.
Беркем миңа җитә алмый,
Һәм узып та китә алмый.
("Запрещено» билгесе).
Миңа юл күрсәтеп тора –
Кара нинди шәп билге!
**Полиция.** Аю дускай, ашыкма,
Нинди билге алдыңда?
**Аю.** "Сәпид"тә йөрергә дигән
Бары тик шушы юлдан.
**Полиция.** Аю дустым, кызыл түгәрәк эчендәге велосипед – йөрергә ярамый дигәнне аңлата. Ә менә бу (зәңгәр түгәрәкне күрсәтә) юл, велосипедлылар өчен дигән.
**Аю.** Рәхмәт, аңладым, полиция иптәш.

2 күренеш.

*(Җәнлекләр җыелып Тычкан өенә киләләр).*
Түгәрәккә басып "Ак калач"ны җырлыйлар.
Тычканнның туган көненә
Без чакырдык кунаклар.
Кунакларның килүенә
Пешердек без коймаклар.
Менә шулай кабарган,
Менә шулай тәбәнәк.
Менә шундый киңлектә,
Менә шундый тарлыкта.
Ак калач, ак калач
Кемне телисең ал да кач.
**Бака.** Тычкан дус, сине туган көнең белән котлыйм. Мин сиңа матур чәчкә алып килдем. (Бирә).
**Тычкан.** Рәхмәт, рәхмәт, дустым. Бу тылсымлы чәчкәдер, монда нindидер рәсемнәр дә бар. Нәрсәләр ясалган икән, яле, алып карагыз. (Таҗларны алалар, андагы юл йөрү билгесен иптәшләренә күрсәтәләр һәм аның нинди билге булуын әйтәләр).
**Тычкан.** Дусларым, әйдәгез өстәл янына, чәйләребез суына. (Утыралар).
**Куян.** Ә мин сиңа бүләккә табышмаклар алып килдем.
**Бергә.** Я, я, әйтеп җибәр. Без табышмакларга җавап табарга яратабыз.

**Куян.** 1) Озын-озын, озын җеп –
Очы каян табылыр. (Юл)
2) Кылга асылына,
Тимергә таяна,
Утыртып чаба
Теләсәң кая. (Трамвай)
**Бүре.** Мин дә табышмак әйтәм.
3) Ике тәгәрмәчле арба
Атсыз да алга чаба. (Велосипед)
**Төлке.** Ә менә минем табышмак.
4) Юл чатында тора батыр,
Күзләре төрле-төрле,
Берсен ача, берсен йома
Аны белә һәр кеше. (Светофор)
**Тычкан.** Рәхмәт, дуслар, табышмакларыгызга мин бик шат.
**Бүре.** Ә менә без Теремкәйгә килгәндә, өч күзле агай күрдек.
**Аю.** Ә-ә, мин беләм аны – ул Светофор. Тычкан дус, мин сиңа күчтәнәчкә шигырь китердем.

Светофор (Г.Юнысова)

1. Озын агайның өч күзе:
   Кызыл, сары, яшел ут.
   Икесе сүнеп тоганда,
   Берсе яна шунда ук.
2. Юл аша чыкканда, һәркем
   Карый шушы күзләргә.
   Һәрбер күзнең – үз фәрманы,
   Һич кирәкми сүзләр дә.
3. Сары күз янса – “Көтеп тор!”
   “Тукта!” – кызыл янганда.
   “Тизрәк бул, алга атла!” –
   Яшел күз елмайганда.

**Тычкан.** Рәхмәт, Аюкай. Бүре дус, ишеттеңме инде Светофор турында.
**Бүре.** Ишеттек, ишеттек. Ә без сиңа бию бүләк итәбез, әйме, Хәйләбикә?
**Төлке.** Бик рәхәтләнеп.

*Бию. (Төлке, Бүре)*

**Аю.** Дуслар, бик озак кунак булдык түгелме? Безгә китәргә вакыт.
**Тычкан.** Юк, юк, дусларым. Күчтәнәчләрегез өчен зур рәхмәт. Ләкин матур бер җыр җырламыйча беркем дә китми.

*Җыр “Светофорның утлары”*

**Кунаклар (**саубуллашалар). Рәхмәт, Тычкан дус. Сау бул.
**Тычкан.** Сау булыгыз, дусларым.

Тәмам.

# Мин барам, барам, барам.

( Әкият)

Борын- борын заманда

Фәрман килгән урманга.

Саескан хәбәр иткән

Ярышнын шарты икән:

“Нәкъ урманның читендә

Светофор тора туктап.

Барып җитәргә кирәк

Юл кагыйдәсен үтәп!”

Бу фәрманны ишетеп,

Әкият геройлары җыелды.

Уйлаштылар, сөйләштеләр

Һәм карар чыгардылар:

“ Йөгереп китәрбез әле,

Барып җитәрбез эле.

Юл билгеләрен танып,

Төгәл үтәрбез әле.”

**Йомры икмәк:**

“ Светофор мине көтә.

Ау-у... тавышым ерак китә...”

Юл билгесен күрмәсәң,

Төлке кабып та йота.

Бүре абзый ашыккан,

Тамагы да бик ачкан,

Борылышны күрмичә,

Сазлыкка кереп баткан.

Самокатта аю элдерә,

Алны-артны карамый.

Поезддан алда чыгу

Һичбер вакыт ярамый!

Беренче булу күңелле!

Исән-сау булу рәхәт!

Юл билгеләрен белгәнгә

Светофор әйтә рәхмәт!

“Әфарин, куян, котлыйм!

Менә призны тот син.

Юл билгеләрен син белдең.

Шуңа ярышта җиңдең!

**Светофор:**

“Билгеләрне саный-саный,

Гомерем юлда үтә.

Әкияттәге хәлләрдән

Гыйбрәт ал!

Кагыйдәләрне үтә! (Автор Фахурутдинова Ф.К.)

*“Әти-әни һәм мин” спорт бәйрәме*

**Кичә барышы.**

**1 нче алып баручы.** Хәерле кич, хөрмәтле әти-әниләр, кадерле балалар! Без бүген сезнең белән шушы якты залга көч сынашырга, ягъни спорт бәйрәменә җыелдык. Шулай ук физик культура белән дә шөгыльләнербез, төрле сорауларга җаваплар табарбыз. Әби-бабаларыбызның “Сәламәт тәндә-сәламәт акыл” дигән асыл сүзләрнең мәгънәсенә төшенербез. Карагыз әле, безнең белән көч сынашырга берсеннән-берсе җитез, берсеннән-берсе кыю, берсеннән-берсе акыллы һәм сәламәт гаиләләр җыелган.

**Шатлыклар күңелебездә,**
**Ал кояш күгебездә.**
**Килгәннәр дуслар кунакка,**
**Ярышлар бүген бездә.**

**2 нче алып баручы**. Здравствуйте, любители спорта! Мы собрались в этом большом, светлом зале, чтобы провести веселые старты.

**Посмотри, друзья вокруг**

**Ребятишек целый круг**

**Рядом с ними папы, мамы.**

**Папы бросили диваны**

**Мамы бросили кастрюли.**

**Все хотят соревноваться,**

**Пошутить и посмеяться,**

**Силу, ловкость показать.**

**Этой встрече все мы рады.**

**Собрались не для награды.**

**Нам встречаться чаще нужно,**
**Чтобы все мы жили дружно.**

**1 нче алып баручы.**

**Килгәннәр безгә кунаклар,**
**Тезелдек үзебез дә.**
**Көрәшик тә, узышыйк та-**
**Ярышлар бүген бездә.**

**2 нче алып баручы.** Ярышларны башлаганчы жюри сайлыйк. Алар бәйгене бәяләп барыр. Әйдәгез командалар белән танышып үтик.

**1 команда "Җитезләр"**

**2 команда "Көчлеләр"**

**1 нче алып баручы.** Әйдәгез, ярышларны башлаганчы гәүдәләрне язып алыйк. Музыкага туры китереп күнегүләр ясап алырбыз.

**2 нче алып баручы.** Ә хәзер бәйгеләрне башлыйбыз.

**Уңыш сезгә, уңыш безгә**
**Елмаеп-көлеп торсын,**
**Шушы бәйге арабызда**
**Дуслык җепләрен сузсын.**

**1 ярыш. "Шар җибәрү".** Командалар тезелешеп басалар. Башта тупны өстән артка җибәрәләр, кире астан алга кайта. Кем тизрәк?

**2 ярыш. "Көнгерәләр уены".** Командалар берешәрләп туп өстенә утырып , билгене урап киләләр.

***Ял минуты.*** "Дәвам ит..." уены

1) Просыпаюсь утром рано

Вместе с солнышком румяным

Заправляю сам кроватку, быстро делаю …. зарядку

2) Не обижен, а надут,

Его по полю ведут.

А ударят –нипочем

Не угнаться за … мячом

3) Этот конь не ест овса,

Вместо ног два колеса.

Сядь верхом, езжай на нем,

Только лучше правь рулем. (Велосипед)

**3 ярыш. "Ракетка белән шар алып бару".** Ракетка өстенә шар куеп идәнгә төшермичә билгене урап килеп, иптәшеңә тапшырасың. Уен шулай дәвам итә.

**4 яыш. " Футбол".** Аяк белән тупны варотага кертергә.

**5 ярыш. “Башка песоклы капчык куеп бару”.** Песоклы капчыкны башка куеп, төшермичә билгене урап килергә. Иптәшең дәвам итә. (Әти-әниләр лабиринт аша үтә.)

**6 ярыш. “Тупны тапшыр”** Тупны алып, йөгереп барып билгене урап килеп, икенче иптәшеңә тапшыр.

Сез ярышта – зирәкләр,
Тормышта – тату гаилә,
Бик тиз фикер йөрттегез,
Дусларга сез терәкләр.

Жюрига сүз бирелә.

**“Теремкәй”.**

(Юл йөрү кагыйдәләрен өйрәнү өчен әкият-тамаша).

**Максат**:
1.Балаларның юл йөрү кагыйдәләре турындагы белемен ныгыту.Юл билгеләрен танырга һәм аера белергә өйрәтү.
2.Светафор төсләрен аера белүләрен ,аның буенча ничек хәрәкәт итүләрен тикшерү.
3.Урамда йөргәндә игътибарлылык тәрбияләү,юл кагыйдәләренә буйсынырга өйрәтү.

1 күренеш.

*Күңелсез генә тычкан керә.*

**Тычкан.** Бүген минем туган көн
Миңа 5 яшь тулган көн.
Бәйрәм итә торган көн.
Ә дусларны чакырырга
Булсын иде “Теремкәй”.
Пирожкилар пешереп
Эчәр идек тәмле чәй.
*(Өйне күрә,әйләнеп йөри).*
**Тычкан** (ишек шакый). Терем-терем-теремкәй,
Теремкәйдә кем яши?
*(Як-ягына карана)*
Берәү дә юк.
Кара, нинди матур өй –
Теләсәң дусларны җый!
Шалтыратып алыйм әле үзләренә, телефон кая икән монда? (“*Телефон” билгесен күрә).* Менә “Телефон” билгесе. *(Телефоннан сөйләшә).*
Минем адрес: Теремкәй, Совет урамы, 25 йорт. “Больница” билгесен тапсагыз. Көтәм сезне!
Теремкәйне җыештырыйм,
Кунакларга бәлеш җитештерим. *(Өйгә кереп китә).*

*Юлга сикереп Әтәч керә.*
**Әтәч.** Кара, миңа сикереп уйнарга нинди сызыклар сызып куйганнар. Әле Тычканга барырга иртәрәк, сикерим рәхәтләнеп.
Кикрикүк, кикрикүк
Сикерик тә сикерик.
Туган көнгә барганчы
Рәхәтләнеп сикерик.
*(Машина кычкырткан тавыш.)*

**Куян** (йөгереп кереп, юлдан тартып ала). Машинага таптала яздың ич, ник юлда сикерәсең?
**Әтәч.** Менә сикерергә матур сызыклар сызганнар ич.
**Куян.** Бу “Җәяүле сукмагы” – зебра дип атала. Әнә аның билгесе. Аның аша юлны гына чыгалар. Ә юлда уйнарга һич ярамый, миңа әнием әйтте.
**Әтәч.** Ярый, алайса, башка җирдә сикерермен. (Китә).

*Куян юлны чыгарга килә.. Каршысына машинада Төлке очрый.*
**Төлке.** Куянкай, куянкай, кая болай ашыгасың?
**Куян.** Тычкан Чи-чи туган көненә чакырды, шуңа ашыгам.
**Төлке.** Ә кайда яши ул Чи-чи?
**Куян.** Яңа гына шалтыратты, Совет урамы, 25 йортта Теремкәйдә яши.
**Төлке.** Әйдә, үзем илтеп куям.
**Куян.** Юк, юк, әни таныш түгел кешеләргә утырма диде.
**Төлке.** Ярый, ярый, ләкин син дөрес юлдан бармыйсың. Менә бу юлны кисеп чык та, урам буенча туп-туры бар. Шунда Теремкәйне табарсың.
**Куян.** Рәхмәт, Төлке апакай. *(Төлке китә).*
**Куян** *( юлны чыгарга килә).* Йөгерим тизрәк, соңга кала күрмим. Бу Төлке апакай дөрес әйттеме икән? *(Каршына милиция чыга).*
**Полиция.**

Туктагыз, гражданин Озынколак.
Кагыйдәне бозмагыз
Машина юлын бары тик
“Зебра” дан үтегез.
Юлдагы бәла-казаларны
Берүк урап үтегез.

**Куян.** Йөгерәм, йөгерәм, ашыгам
Тизрәк бәлеш ашарга.

**Полиция.** Әллә син юл кагыйдәләрен бер дә белмисең, инде, Куянкай?
**Куян.** Зебраны беләм, әни әйтте. Ә кагыйдәләрне белмим.
**Полиция.** Зебраны гына түгел, юл йөрү кагыйдәләрен бөтен кеше дә белергә тиеш. Әйдә мин сине юл аша чыгарам. (Озата).

“*Остановка автобуса” билгесе янында Бүре тора. Төлке килеп туктый.*
**Бүре.** Автобус юк

Вәт кайгы.
Туган көнгә соңарам,
Тычканны котлый алмам.

**Төлке** (килә). Әй, Сорыкай, син кая?

**Бүре.** Кунакка соңга калам.
**Төлке.** Әйдә, утыр, тизрәк.
**Бүре.** Җилдерик җитезрәк.
**Төлке** (машинасы сүнә). Мотор сүнде. Ярдәм ит.
Машинаны арттан эт. (Бүре этеп бара).
**Төлке.** Бу “больница” билгесеме?
Ә Теремкәй күренәме?
**Бүре** (арыган, тирен сөртә).
Моннан йөгереп үт дигән
Күрәсеңме билгене?
(“Осторожно дети” билгесе).
**Светофор** (чыга). Туктагыз, ашыкмагыз!
Кызыл утка чыкмагыз!
Сары утта көтегез.
Яшел булгач, китегез!
**Бүре.** Бу кем соң ул?
Өй-рә-тә.
**Төлке.** Светофор – бу.
Хәрәкәтне көйләтә.
(Светофорга билгене күрсәтә).
**Бүре.** Монда йөгереп йөрергә күрсәткән.
**Светофор.** Юк, юк, дустым, бу билге
Ашыкмаска өйрәтә.
Юлда балалар булыр дип
Шоферларны кисәтә.
**Бүре, Төлке.** Ярый, ярый, аңладык. (Китәләр).
*Велосипедта Аю килә.*
**Аю.** Менә нинди тигез юл
Йөгерәмен “сәпид”тә.
Беркем миңа җитә алмый,
Һәм узып та китә алмый.
(“Запрещено» билгесе).
Миңа юл күрсәтеп тора –
Кара нинди шәп билге!
**Полиция.** Аю дускай, ашыкма,
Нинди билге алдыңда?
**Аю.** “Сәпид”тә йөрергә дигән
Бары тик шушы юлдан.

**Полиция.** Аю дустым, кызыл түгәрәк эчендәге велосипед – йөрергә ярамый дигәнне аңлата. Ә менә бу (зәңгәр түгәрәкне күрсәтә) юл, велосипедлылар өчен дигән.

**Аю.** Рәхмәт, аңладым, полиция иптәш.

2 күренеш.

*(Җәнлекләр җыелып Тычкан өенә киләләр).*

Түгәрәккә басып "Ак калач"ны җырлыйлар.

Тычканнның туган көненә
Без чакырдык кунаклар.
Кунакларның килүенә
Пешердек без коймаклар.
Менә шулай кабарган,
Менә шулай тәбәнәк.
Менә шундый киңлектә,
Менә шундый тарлыкта.
Ак калач, ак калач
Кемне телисең ал да кач.

**Бака.** Тычкан дус, сине туган көнең белән котлыйм. Мин сиңа матур чәчкә алып килдем. (Бирә).

**Тычкан.** Рәхмәт, рәхмәт, дустым. Бу тылсымлы чәчкәдер, монда ниндидер рәсемнәр дә бар. Нәрсәләр ясалган икән, яле, алып карагыз. (Таҗларны алалар, андагы юл йөрү билгесен иптәшләренә күрсәтәләр һәм аның нинди билге булуын әйтәләр).

**Тычкан.** Дусларым, әйдәгез өстәл янына, чәйләребез суына. (Утыралар).

**Куян.** Ә мин сиңа бүләккә табышмаклар алып килдем.

**Бергә.** Я, я, әйтеп җибәр. Без табышмакларга җавап табарга яратабыз.

**Куян.** 1) Озын-озын, озын җеп –
Очы каян табылыр. (Юл)
2) Кылга асылына,
Тимергә таяна,
Утыртып чаба
Теләсәң кая. (Трамвай)

**Бүре.** Мин дә табышмак әйтәм.
3) Ике тәгәрмәчле арба
Атсыз да алга чаба. (Велосипед)

**Төлке.** Ә менә минем табышмак.
4) Юл чатында тора батыр,
Күзләре төрле-төрле,
Берсен ача, берсен йома

Аны белә һәр кеше. (Светофор)

**Тычкан.** Рәхмәт, дуслар, табышмакларыгызга мин бик шат.

**Бүре.** Ә менә без Теремкәйгә килгәндә, өч күзле агай күрдек.

**Аю.** Ә-ә, мин беләм аны – ул Светофор. Тычкан дус, мин сиңа күчтәнәчкә шигырь китердем.

Светофор (Г.Юнысова)

1. Озын агайның өч күзе:
   Кызыл, сары, яшел ут.
   Икесе сүнеп торганда,
   Берсе яна шунда ук.
2. Юл аша чыкканда, һәркем
   Карый шушы күзләргә.
   Һәрбер күзнең – үз фәрманы,
   Һич кирәкми сүзләр дә.
3. Сары күз янса – "Көтеп тор!"
   "Тукта!" – кызыл янганда.
   "Тизрәк бул, алга атла!" –
   Яшел күз елмайганда.

**Тычкан.** Рәхмәт, Аюкай. Бүре дус, ишеттеңме инде Светофор турында.

**Бүре.** Ишеттек, ишеттек. Ә без сиңа бию бүләк итәбез, әйме, Хәйләбикә?

**Төлке.** Бик рәхәтләнеп.

*Бию. (Төлке, Бүре)*

**Аю.** Дуслар, бик озак кунак булдык түгелме? Безгә китәргә вакыт.

**Тычкан.** Юк, юк, дусларым. Күчтәнәчләрегез өчен зур рәхмәт. Ләкин матур бер җыр җырламыйча беркем дә китми.

*Җыр "*

**Кунаклар (**саубуллашалар). Рәхмәт, Тычкан дус. Сау бул.

**Тычкан.** Сау булыгыз, дусларым.

Тәмам.

# **Сөмбелә бәйрәме**

Максат: балаларны татар халык бәйрәмнәренең берсе - Сөмбелә бәйрәме белән таныштыру.
Бурычлар:
1.Балаларның сөйләмен үстерергә ярдәм итү.
2.Балаларның игътибарын, үзләштерү, кабул итүне, сенсор тою сәләтен, сорауларга җавап бирү осталыгын үстерү.
3.Татар халык бәйрәмнәренә кызыксыну уяту һәм татар халкына мәхәббәт тәрбияләү.

*Балалар залга керә.* ***Музыка №1.***

**Алып баручы:**
Ни арада җәй үтте,
Матур көз килеп җитте.
Шатлык тулы бу бәйрәмне
Балалар күптән көтте.

Рәхим итегез,
Көзге бәйрәмгә.
Яфраклар тотып,
Бер биик, әйдә.

**Яфраклар белән бию.** ***Музыка №2.***

**Алып баручы:**
И, балалар, күрегез,
Тышта әнә килде көз.

**Балалар:**
Әйе, әйе, күрәбез,
Көз килгәнен беләбез.

**Алып баручы:**
Я әйтегез, сөйләгез,
Ничек килә икән көз?

**Искәндәр:**
Менә көз килде.
Салкынча җилле.
Агачларда яфраклар
Саргайган инде.

**Алия.**
Бездәге кошлар
Көньякка китте.
Сизелмичә дә
Җылы җәй үтте.

**Динә.**
Җиргә яфрак коелган,
Сап-сары кeләм булган.
Яфракларны без җыярбыз,
Букет ясап куярбыз.

**Роберт.**
Көз көннәре килеп җитте,
Хушлашабыз җәй белән.
Бөтен җиргә яфраклардан
Алтын келәм җәелгән.

**Айваз:**
Көз көннәре бик күңелле,
Бик күп җимешләр пешә.
Помидор, карбыз өлгерә,
Алмалар өзелеп төшә.

**Данил:**
Көз! Көз! Көз!
Көзсез күңелсез.
Алтын-сары яфраклар да
Коелмый синсез.

**Адель.**
Көз ашыга агачларга
Үз бизәген салырга:
Урманнарны, болыннарны
Буяп китә сарыга.

**Җыр "Көз килә".** ***Музыка № 3.***
(А.Минһаҗев сүз., Р.Сәрвәров муз.)
Шаяра әле күбәләк
Үтсәләр дә җәйләре.

Ә урамга килеп керде,
Килде яфрак бәйрәме.

Кушымта:
Нинди генә төсләре юк,
Күреп исең китәрлек.
Яфрак ява, яфрак ява
Юлыбызга түшәлеп.

Өлгереп җиткән миләшләр
Утлар шикелле яна.
Ә яфраклар бөтерелеп
Ява да ява, ява.

Кушымта.

Югалмаган икән әле
Төсләрнең яшеле дә.
Ясап яфрак бәйрәмнәре
Килә көз әкрен генә.

**Алия.**
Яфракларны күр әле
Алтын төскә кергәннәр.
Бар дөньяны күмгәннәр.
Җил чыкканда шаулашалар,
Оча-оча уйнашалар,
Һавада әйләнәләр
Һәм җиргә сибеләләр.

**Айваз.**
Киң болыннарда,
Урман-кырларда,
Агачлар, гөлләр
Кибеп сулдылар.
Уйсу җирләрдә
Елга, күлләрдә,
Көзге салкыннан
Сулар туңдылар.
Көннәр суынды,
Чишмәләр тынды,
Безне калдырып

Кошлар да китте.

**Карина.**
Миновало лето.
Осень наступила.
На полях и в рощах
Пусто и уныло.
Птички улетели.
Стали дни короче.
Солнышка не видно.
Темны, темны ночи.

**Артем.**
Ходит осень по дорожке,
Промочила в лужах ножки.
Льют дожди и нет просвета.
Затерялось где-то лето.
Ходит осень, бродит осень.
Ветер с клёна листья сбросил.
Под ногами коврик новый,
Жёлто-розовый – кленовый.

**Җыр “Осень наступила”** ***Музыка № 4***
Осень, осень наступила,
Листья осыпаются.
Солнца нет и потемнело,
Дождик начинается.

Припев:
Кап-кап на дорожки,
Кап-кап на ладошки.
Дождик землю поливай,
С нами поиграй.

Паучки, жучки и мошки
Прячутся, скрываются,
И в далекую дорогу
Птички собираются.

Припев.
Кап-кап на дорожки,
Кап-кап на ладошки.
Дождик землю поливай,
С нами поиграй.

**Алып баручы:** Карагыз әле, хат! Кызык, кемнән икән ул? Ачып карыйк әле. *(Конвертны укый).*

“Ләйсән” балалар бакчасына йөрүче балаларга.

Көзбикәдән диелгән. Укыйбызмы?

Кошларны озатып,
Җылы якларга.
Үлənне буяп,
Сары төсләргә.

Тиздән, бик тиздән,
Сагынып сезне
Килермен, дуслар,
Көзге бәйрәмгә!

**Алып баручы:** әйдәгез, Көзбикә килеп җиткәнче тагын бер җыр җырлап алыйк.

**<u>Җыр “Осень в лесу”</u>** ***Музыка № 5***

Осень, осень, осень
Снова к нам пришла
Осень, осень ,осень
Чудная пора
В золотом наряде
Парки и сады
Осень, осень ждали
С не терпеньем мы.

Припев:
Парам-пам-пам
Парам-пам-пам

А в лесу чудесно
Просто красота
И тропинка тянется
Прямо вдоль пруда
Наберём калины
Ягоды висят
За пенёчком прячутся
Шляпки у опят.

Припев:
Парам -пам-пам
Парам-пам-пам

Белка на поляне
Шишечки грызёт
Ёжик босоногий
По лесу идёт
На спине у ёжика
Яблоки, грибы
Ёжик правда любишь?
Осени дары.
Да ,да люблю
Да, да люблю

Припев:
Парам пам-пам
Парам пам-пам.

*(Көз керә)* ***Музыка № 6***

**Данил:**
Исәнме, Көз, алтын көз.
Безне сагынып килдеңме?
Агачларга, куакларга
Сары чуклар элдеңме?

**Көз:**
Мин – Көз. Килдем сезгә.
Көзге байлык кулымда.
Муллык белән байлык телим
Кем очраса юлымда.
Исәнмесез, нәни дуслар!

**Балалар:**
Исәнме, Көзбикә!

**Алып баручы:**
Исәнме, Көзбикә! Әйдә уз, рәхим ит бәйрәмебезгә.

**Хоровод «Подарки Осени».** ***Музыка №7***

Хор:

Осень, осень, осень золотая,
Наша гостья, гостья дорогая!
Хорошо, что ты пришла,
Что нам, осень, принесла?
Соло:
Принесла я вам с полей
Колоски пшеничные.
Будут, будут у детей
Пироги отличные.

Хор:
Осень, осень, осень золотая,
Наша гостья, гостья дорогая!
Хорошо, что ты пришла.
Что нам, осень, принесла?
Соло:
Помидоры, Огурцы
Принесла вам с грядки,
И капусту, и бобы.
Кушайте, ребятки.

Хор:
Осень, осень, осень золотая,
Наша гостья, гостья дорогая!
Хорошо, что ты пришла,
Что нам, осень, принесла?
Соло:
Чудо-яблоки для вас
Принесла из сада.
Угощаю всех сейчас,
Кушайте, ребята.

**Көз:**
Сезнең янга ашыгып
Мин урманнан килгәндә
Шаян яңгыр мине куды,
Аягымны чылатты,
Юлларны пычыратты,
Ай-яй, яңгыр, куркытты.

**Алып баручы:**
Куркыныч түгел
Яңгырлар безгә.
Кәлүшләрне киярбез

Йөгерешеп уйнарбыз.

**<u>Уен «Галошлар киеп йөгерү» </u>*Музыка №8***
*(балалар ике командага бүленәләр. Һәр уенчы аягына парлап галошларны кия, зонтикка кадәр йөгерә, урап килеп икенче уенчыга галошларны бирә. Эстафета дәвам итә).*

**Көз:** Менә яңгыр да бетте, барлык җыелып торган сулыклар кипте.
Мин сезгә, балалар, үзем белән урманга барырга тәкъдим итәм. Хәзер урманда бик матур!

*(Балалар Көз артыннан тотынып барып, түгәрәккә басалар).* ***Музыка № 9***

**Көз:** Менә без сезнең белән урманга да килеп җиттек. Тирә-юньдә нинди матурлык! Ишетәсезме...кошлар сайрый, җил исә.... ***Музыка № 10*** (*кошлар тавышы, җил тавышы)*
*(Чыршы агачы янына алып килә).*
Карагыз әле бу агачка, сез аны таныйсызмы? *(Әйе, чыршы).* Ләкин ул гади чыршы түгел, аңа табышмаклар язылган кәгазьләр эленгән. Табышмакларны чишәргә булышасызмы?

**<u>Табышмаклар чишү:</u>**

Үзе тук була,
Елап яшь коя.
Кошны, гөлләрне
Еракка куа. **(Көз)**

Утыра бер ак чүлмәк,
Өстенә кигән йөз күлмәк. **(Кәбестә)**

Җир астында алтын казык,
Алдык без аны казып. **(Кишер)**

Озын-яшел түтәлдә,
Сары, тозлы – кисмәктә. **(Кыяр)**

Итләч, йомры яшелен,
Өзеп алдым, яшердем.
Гаҗәпләндем бераздан,
Кояшсыз да кызарган. **(Помидор)**

Турыйсың, турыйсың,
Тураганда елыйсың. **(Суган)**

Төбе алмалы
Башы чалмалы. **(Бәрәңге)**

Кызыл эчле яшел өй,
Тәрәсез, ишексез.
Авыз итеп карасаң,
Балдан татлы һичшиксез. **(Карбыз)**

Мочит поле, лес и луг,
Город, дом и всё вокруг!
Облако и туч он вождь,
Ты же знаешь, это - …**(дождь)**



Холода их так пугают,
К тёплым странам улетают,
Петь не могут, веселиться,
Кто собрался в стайки? … **(птицы)**

Вот на ножку купол – гриб,
Он от ливня защити.
Не намокнет пешеход,
Если спрячется под… **( зонт)**

Он не ведает границ,
Он летит быстрее птиц.
Кто свободней всех на свете?
Догадались? Это … **(ветер)**

**Көз.** Рәхмәт, балалар, сез барлык табышмакларның да җавабын дөрес таптыгыз.
**Музыка № 11** (җил тавышы).

**Көз.** Урманда көчле җил исеп барлык агачларның да яфракларын койган. Әйдәгез әле без хәзер сезнең белән бу агачларга туры килгән яфракларны элеп, агачларны киендерик.

**Уен “Агачны киендер”.**



*(Өч бала катнаша. Фланелеграфка өч агач беркетелә. Балалар яфраклар арасыннан үзенең агачына туры килгән яфракны алып агачка беркетә).*

**Алып баручы:** Көз, синең урманда бик күңелле. Без сиңа балалар белән бер җыр җырлыйсыбыз килә. Тыңла әле.
**Җыр «Яфрак бәйрәме»** ***Музыка № 12***

**Көз: (***кулчатыр күрсәтә).* Мин кичә урман буйлап барганда кулчатыр таптым. Әйдәгез әле, нәни дусларым, кулчатырлар белән биеп алыйк.
***Музыка № 13***
(*Балалар урындыкларга утыралар).*

**Көз:** Ә хәзер без сезнең белән урман җәнлекләре кышка ничек әзерләнүләрен карарбыз. ***Музыка № 14***
*(Айваз, Динә, Искәндәр аю, куян, тиен киемнәреннән залга чыгып басалар.)*

**Көз:**
Менә тиен, менә куян,
Аю дустым да монда.
Көзне ничек каршылыйлар
Сорашыйк әле барын да.

**Куян:**

Вакыт соры тунымны
Ак тунга алмашырга.
Җәен соры, кышын ак
Миңа шулай яхшырак.

**Куян.** Көзбикә, син миңа тунымны табарга булышырсыңмы**?**

**Көз:** Куянкай, табып бирермен туныңны сиңа. Әлегә әйдә син безнең белән түгәрәккә басып уен уйнап ал.

**«Ап-ак куян утыра…»**
Ап-ак куян утыра,
Колакларын селкетэ.
Менэ шулай, менэ шулай
Колакларын селкетэ.

Ана тик тору кыен,
Жылыта ул тэпиен.
Менэ шулай, менэ шулай
Жылыта ул тэпиен.

Куян тик торса туна,
Сикергэли ул шуна.
Менэ шулай, менэ шулай
Сикергэли ул шуна.

**Тиен:** (гөмбәләр салган кәрҗин күтәргән)
Ашыгам, чабам, йөгерәм
Гөмбәләрне киптерәм.
Чикләвекләр, шишкаларны
Кышка җыеп бетерәм.

**Көз:**
Яхшы, тиен, син тырыш
Тамагың тук булыр кыш.

Әйдәгез, балалар, тиенгә кышка гөмбә әзерләргә булышабыз.

**<u>Уен “Гөмбәләрне баугa эл</u>”** *(уенда 2 бала катнаша. Җирдә яткан гөмбәләрне алып бауга эләләр.)*
**Тиен:** Ай-яй, дусларым, сез бит агулы гөмбәләрне дә җыйгансыз. Аларны бит ашарга ярамый.
**Көз:** Ә нинди ашарга яраклы гөмбәләрне беләсез?

**Балалар:** Баллы гөмбә-опята, гөрәҗдә-грузди, маслята- майлы гөмбә, белый гриб-ак гөмбә, сморчки-кәҗә гөмбәсе, подберезовик-каен гөмбәсе, подосиновик-усак гөмбәсе, кызыл гөмбә.

**Көз:** Бу гөмбәләр арасында кайсы гөмбәләрне ашарга ярамый?

**Балалар:** Чебен гөмбәсе...

**Аю:** *(Кулына шишкалар салынган кәрҗин тоткан аю уртага чыгып баса)*

Көз артыннан кыш килә.
Җылы өнемә кереп
Йоклар вакытлар җитә.
Татлы баллар күрермен,
Төшләремдә йоклагач
Уянырмын яңадан
Мин ямьле язлар җиткәч.

**Көз:**
Ә, дусларым, сезгә уен-
Аюга булышыгыз.
Яшелчә-җимешләрне
Кәрҗингә тутырыгыз.

**<u>Уен «Яшелчә, җиләк-җимешләрне аеру»</u>** (Кечкенәләр, уртанчылар төркеме уйный).

**Көз:** Нәни дусларыбыз, безнең сезнең белән саубуллашу вакытлары килеп җитте. Мин  сезгә көзге күчтәнәчләр тулган кәрҗинемне бүләк итәм, балалар бакчасына кайткач ашарсыз.
Саубуллашыр сәгать җитте
Арттан куа салкын кыш.
Тагын бер елдан килермен
Ә хәзергә хушыгыз!
**Балалар:** Сау бул, Көзбикә, сау булыгыз, дуслар!

(Балалар поездга утырып кайтып китәләр). ***Музыка № 15***

**Өч чучка баласының Яңа ел маҗаралары.**

*Балалар залга кереп утыра.* ***Музыка № 1***

**Тәрбияче:**
Нинди гаҗәп:
Ап-ак булып кар яуганда,
Күңелебез шатлык белән тулган мәлдә,
Җыйналдык без бүген шушы матур залга,
Кыш бабайны каршыларга, уйнарга һәм җырларга!
- Кадерле, балалар! Хөрмәтле әти-әниләр, килгән кунаклар! Барыгызны да Яңа ел бәйрәмнәре белән котлыйбыз! Һәрбарчагызга киләсе елда күңел тынычлыгы, гаилә бәхете, балаларыбызның сау-сәламәт булуын телибез.
- Яңа ел алдыннан төрле могҗизалар, кызыклы хәлләр дә була. Әйдәгез, без дә шуларны карап алыйк әле.

***Музыка № 2*** *(Өч чучка баласы йөгереп-җырлап керәләр).*

Без өч чучка баласы, баласы, баласы
Яратабыз уйнарга, уйнарга, уйнарга
Курыкмыйбыз һичкемнән, һичкемнән, һичкемнән,
Хәтта соры бүредән, бүредән, бүредән.

Без өч чучка баласы, баласы, баласы
Ниф-Ниф, Наф-Наф, Нуф-Нуф.
Курыйкмыйбыз һичкемнән, һичкемнән, һичкемнән,
Хәтта соры бүредән, бүредән, бүредән.

***Музыка № 3*** *(Елаган тавыш).*

**Наф-Наф.** Тсс! Монда кемнеңдер елаган тавышы килә.
**Ниф-Ниф.** Һии! Еласын, ә без уйныйбыз.
***Музыка № 3*** *(Елаган тавыш).*
**Наф-Наф.** Тукта! Тыңлагыз! Кемдер бик каты елый, әйме, Нуф-Нуф?
**Нуф-Нуф** *(тыңлый).* ***Музыка № 3*** *(Елаган тавыш).* Әйе шул.
*(Эзлиләр).* *(Елкада ак бияләй эленеп тора, янына киләләр).* Әһә, менә кем ул елый.
**Ниф-Ниф.** Ник елыйсың, уйнарга комачаулыйсың.

***Музыка № 4***

**Бияләй.** Сез шатланасыз, ә Карчәчәк югалды. Өч көн инде. Менә мине дә төшереп калдырган.

**Наф-Наф, Нуф-Нуф.** Карчәчәк югалган?!

***Музыка № 5***

**Бияләй.** Урманда Соры бүре бар, ди, шул аны урлап киткәндер.

**Ниф-Ниф, Наф-Наф, Нуф-Нуф** *(бергә).* Карчәчәк югалгач, Яңа ел да килми, безгә бүләкләр дә булмый.

**Ниф-Ниф.** Ә мин ул Бүрене акылга утыртам. Хәзер мин аны табып.

**Наф-Наф.** Ниф-Ниф, Бүре бик куркыныч җәнлек, онытма!

**Ниф-Ниф.** Курыкмыйм мин бүредән / 3 тапкыр
Хәзер табып бетерәм / 3 тапкыр

*(Җырлый-җырлый масаеп чыгып китә).*

**Наф-Наф.** Нуф-Нуф, аңа ярдәм итәргә кирәк, ул Яңа ел кичендә Бүрегә шашлык булырга мөмкин.

**Нуф-Нуф.** Әйе, әйдә киттек. *(Чыгып китәләр).*

*(Ниф-Ниф җырлап керә. Бу вакытта Бүре елка төбенә кереп ята, йоклый).*

**Ниф-Ниф.** Мин сиңа хәзер, карт Бүре, күрсәтәм күрмәгәнеңне. *(Тибә, сугыша, Бүре карап тора).* Тотсам тефтели ясыйм мин синнән.

**Бүре.** Тефтели тәмле инде тәмлелеккә, симез, майлы чучка тефтелие – тәмле. *(Ниф-Нифка).* Әй, нәрсә тавышланасың? *(Тота).*

**Ниф-Ниф.** Мин...мин...гөмбә җыям.

**Бүре.** Ха-ха, кыш көнеме?

**Ниф-Ниф.** Мин...мин...тефтели ясыйм.

**Бүре.** Ха-ха, миннәнме? Хәзер мин синнән тефтели ясыйм. *(Ниф-Ниф кача).(Бүре тотып, өенә алып кайта. Ишекне бикли.)*

***Музыка № 6***

**Бүре.** Тыныч кына утыр, мин утын гына җыеп кайтам. Яңа елга шашлык ясарбыз. *(Чыгып китә).*

*2 дуңгыз баласы өй янына киләләр. “Волк” дигән язуны укыйлар, тәрәзәдән карыйлар, шакыйлар.*

**Наф-Наф.** Ниф-Ниф, син мондамы?

**Ниф-Ниф.** Ой, дусларым, сез мине эзләп килдегезме? Мин инде беттем дип уйлаган идем. Сез мине коткарырсызмы?

**Нуф-Нуф.** Тыныч бул, Ниф-Ниф. Син монда үзеңгенәме?

**Ниф-Ниф.** Әйе, бүре Карчәчәкне ашагандыр. Монда беркем юк. Монда нindидер капчык кына бар.

**Наф-Наф, Нуф-Нуф.** Капчык??? Кыш бабайныкы?

**Наф-Наф.** Ярар, без сиңа ярдәм итәрбез, курыкма гына. *(Качалар).*

*Бүре кайта.*

**Бүре.** И-и, минем симез, тәмле чучкам, борчылып беттеңме. *(Ишекне ача).*

***Музыка № 6***

*Ниф-Ниф капчык белән суга да чыгып кача.*

**Наф-Наф, Нуф-Нуф** *(кар аталар).* Менә сиңа! Менә сиңа!
**Бүре.** Ой-ой, ярдәм итегез! Алыгыз бу дуңгыз балаларын.

*Карчәчәк керә.*
**Карчәчәк.** Нинди тавыш бу?
**Бүре.** Карчәчәк, коткар бу дуңгыз балаларыннан. Тефтели ясыйлар болар миннән.
**Наф-Наф.** Ул безнең Ниф-Нифтан шашлык ясый язды. Әнә утын да җыеп кайтты.
**Бүре.** Ююк, ышанмагыз, мин бит веги-веги-тари-тари...
**Ниф-Ниф.** Нәрсә, вегитарианец димәкчеме әллә?
**Бүре.** Әйе.
**Наф-Наф.** Ә утын?
**Нуф-Нуф.** Ә шашлык?
**Бүре** *(елап).* Мин бит Ниф-Нифне үземә Яңа ел каршыларга иптәш булсын дип урладым. Минем бит дусларым да юк.
**Карчәчәк.** Әһә, минем бабайның тылсымлы капчыгы монда булырга тиеш.
**Наф-Наф, Нуф-Нуф, Ниф-Ниф** *(бергә).* Тылсымлы???
**Карчәчәк.** Әйе, әнә күрдегезме бүредән вегитарианец ясаган. Дуслар таптырган.
**Наф-Наф, Нуф-Нуф, Ниф-Ниф** *(бергә).*Ә-ә-ә!
**Карчәчәк.** Әйдәгез, дусларым, бүрене дә балалар янына бәйрәмгә чакырыйк.
**Тәрбияче.** Балалар, бүре бездә бәйрәмдә калсынмы?
**Карчәчәк.** Әйдәгез чыршының утларын кабызып, Кыш бабайны каршыларга әзерләник. Ә, Сорыкай, син Кыш бабайга каршы бар, тизрәк бәйрәмгә ашыктыр. Дусларым, әйдәгез чыршының күңелен күреп, җыр җырлап алыйк.

**Җыр "Чыршы янында".** ***Музыка №7***

Яшел чыршы тезелешеп
Әйләнәбез тирәндә.
Куанабыз яңа елга
Син кунакка килгәнгә.

Җәй көне җиләк җыярга
Урманга барган идек.

Ямьле чыршы яңа елга
Кунак булып кил-дидек.
Рәхмәт менә син килгәнсең
Әйләнәбез тирәңдә.
Яңа һөнәрләр өйрәндек
Яңа елга килгәндә.

Яшел чыршы тезелешеп
Әйләнәбез тирәңдә.
Куанабыз яңа елга
Син кунакка килгәнгә.

**Карчәчәк.** Чыршының утлары һаман янмый. Ә бәлки сез шигырь дә сөйләп алырсыз.

**Айваз.** Безгә бүген Кыш бабай
Зур бәйрәм бүләк итте.
Яңа ел бәйрәменә
Чыршы да килеп җитте.

**Динә.** Бүген чыршы безне тыңла,
Бүген безгә карап тор.
Тышта буран котырса да
Син, Чыршыкай, көлеп тор.

*(Чыршының утлары яна).*

**Галимов Искәндәр.** Яңа елны каршыларга
Без чыршыны бизәдек.
Уенчык аю-куяннар,
Шалтыравыклар элдек.

Чыршы тагын матурланды
Төсле йолдызлар янгач.
Аллы-гөлле нурга чумды
Төсле утлар кабынгач.

**Роберт.** Возле елки в Новый год
Водим, водим хоровод.
Елочка, красавица
Детям очень нравится.
Вот она какая
Стройная, большая.

**Данил.** Ямь-яшел ылысларыңа
Уенчыклар эленгән.

Безгә киләсен белгән ул
Шуңа матур киенгән.

**<u>Җыр “Хоровод”.</u>** ***Музыка № 8***

**Тәрбияче.** Балалар, безнең бүре дә югалды, Кыш бабай да никтер күренми. Әйдәгез аны чакырып карыйк.

**Бергә.** Кыш бабай! Ауу!
Кыш бабай! Ауу!

*Кыңгырау тавышы.* ***Музыка № 9*** Кыш бабай керә.

**Кыш бабай.** Исәнмесез, кызларым, улларым,
Күңелем нурлары!
Кар бураннар туздырып,
Ерак юллар үттем мин.
Сезгә килеп җиттем мин.
Сез дә мине көткәнсез
Чыршы бизәп куйгансыз.
Җем-җем яна утлары
Яктыртсын ул юлларны.

**Радель.** Әй, Кыш бабай, Кыш бабай,
Хуш киләсең, уз бире.
Шатланышып җыр белән
Каршылыйбыз без сине.

**<u>Җыр “Кыш бабай”.</u>** ***Музыка № 10*** (Кыш бабайны урап әйләнеп җырлана).

Агачларга бәсләр элеп
Сурәтләрен тәрәзәгә
Ясап куйган Кыш бабай,Кыш бабай
Ясап куйган Кыш бабай.

Рәсемнәре бигрәк матур
Сокланып карап туймаслык
Оста икән Кыш бабай,Кыш бабай
Оста икән Кыш бабай.

Өреп китсә, сулар ката
Елгаларга бозлар ята
Тылсымлы да Кыш бабай,Кыш бабай

Тылсымлы да Кыш бабай.

Тылсымлы да Кыш бабай.
Куәтле дә Кыш бабай.
Оста икән Кыш бабай.
**Кыш бабай.** Рәхмәт, балалар, минем турында күп беләсез икән. Ә менә бу матур кыз кем икән?
**Балалар.** Әйе. Бу – Карчәчәк.
**Карчәчәк.** Әйе шул мин – Карчәчәк
Кардан йолдызлар ясап
Җир өстенә яудырам
Каплыйм җирне кар белән.
Кыш көне мин – Карчәчәк,
Язга чыккач – Алчәчәк.
Сезне чын-чын күңелдән
Котлыйм Яңа ел белән!
**Тәрбияче.** Рәхмәт, Кыш бабай! Рәхмәт, Карчәчәк!
**Кыш бабай.** Кызым, түргә үтикче
Кунак булып китикче.
Чыршы тирәли әйләнеп
Берне биеп үтикче.

**Җыр "Чыршы"** ***Музыка № 11*** (Чыршы тирәли әйләнеп бию)

Килче, Яңа ел,
Уйныйбыз бергә.
Чәчкәле-гөлле,
Рәхәт киң илдә.

Их, безнең чыршы,
Ул нинди купшы!
Янында күмәк
Уйнавы яхшы.

Әйдә, Ак бабай.
Сине көттек без.
Сикереп уйнарга
Сагынып беттек без.

Килче, Кыш бабай,

Җырлыйбыз бергә.
Яңгырасын шат җыр
Бәхетле илдә!

**Тәрбияче.** Кыш бабай, азрак ял итеп ал. Ә безнең балалар синең күңелне күреп, һөнәрләрен күрсәтерләр.

**Адель.** Салкын саф һава
Йомшак кар ява.
Урамга чыксаң
Битләр кызара.

**Данил.** Уянып бүген иртән
Карасам тәрәзәгә
Ак сакаллы Кыш бабай
Кар алып килгән безгә.

**Булат.** Кыш бабай,
Килдең син безгә
Кунак булырсың
Кер өебезгә.

**Раяз.** Кыш бабай
Бүләкләр өләшә.
Тәрәзәдән карый да
Шаян ай көнләшә.

**Искәндәр.** Конфет, шоколад өләшә
Бүләк бирә һәркемгә.
Яңа ел, чыршы бәйрәме
Булсын иде һәр көндә.

**Алия.** Кыш бабай, мине
Бүген син макта.
Бер яшькә үстем
Син килгән чакта.

**Айваз.** Кыш бабай килгән
Ап-ак тун кигән.
Көтә кем генә
Чыгар дип өйдән.

Чыксаң чеметә,
Битне өшетә.
Менә шул аның
Бөтен эше дә.

**Искәндәр.** Снег идет, снег идет
Скоро будет новый год.
Дед Мороз к нам придет
Всем подарки принесет.
**Роберт.** Дед Мороз пришел на елку
Рады мы его встречать.
Будем весело кружиться,
Вокруг елки танцевать.
**Тәрбияче.** Кыш бабай, кара әле, нинди матур Кыш бабайлар килгән безгә.
**Кыш бабай.** Һай, минем дә яшь чаклар бар иде.
**Тәрбияче.** Әйдә, Кыш бабай, яшь чакларны искә төшереп биеп алыйк.

**Бию "Кыш бабайлар".** ***Музыка № 12***

**Дарина.** Ах, какой хороший
Добрый Дед Мороз.
Елку нам на праздник
Из леса принес.

Огоньки сверкают
Красный, голубой.
Хорошо нам елка
Весело с тобой.
**Радель.** Ерактан, суык якларда
Боз чанага утырып,
Бәйрәмгә килде Кыш бабай
Күчтәнәчләр тутырып.

Кулларында боз таягы
Сакалы җиргә тигән.
Ә янында сылу бер кыз,
Энҗе кардан киенгән.

Сылу кызың, энҗе кызың
Ул синең куанычың.
Бергә йөри, синнән калмый
Бәләкәй юанычың.

Балаларга, Яңа елда
Күчтәнәчләр тарата.

Биеп, җырлап, көлдерә дә
Куандырып калдыра.

**Аделина.** Мы встречаем Новый год,
Украшаем елку.
Нарядили огоньками
Каждую иголку!

Написали мы письмо
Дедушке Морозу.
Новый год встречаем мы
Дружно и серьезно!

Пусть несет подарки нам,
Сладости, игрушки.
Новый год для всех ребят
Праздник самый лучший!

**Вильдан.** Кыш бабай! Безнең белән
Күптән таныш инде син.
Ни өчен соң Кыш әбине
Бер дә алып килмисең?

Безгә дигән бүләкләрне
Ул үзе тутырамы?
Аннары, сине озаткач,
Гел өйдә утырамы?

Безнең белән уйнарга
Уе бардыр аның да.
Кыш әбине дә калдырма
Тагын килгән чаныңда.

**Карчәчәк.** Кыш бабай, балалар бик уңганнар, әйдә без дә аларга үзебезнең һөнәрне күрсәтик булмаса.

**Кыш бабай.** Ай, рәхмәт, балалар, бик күп шигырьләр өйрәнгәнсез. Әйдәгез бер җырлап-биеп алыйк.

**<u>Җыр “Мы тебя так долго ждали, дедушка”</u>** ***Музыка № 13***

Мы тебя так долго ждали, Дедушка!
По шагам тебя узнали, Дедушка!
Целый год мы вспоминали, Дедушка,

Как с тобою танцевали, Де -ду -шка!

Припев:
Выставляй скорее ножку:
пяточка, носочек,
А потом другую ножку:
пяточка, носочек.
Поверни свои ладошки
вверх и вниз
И ещё совсем немножко по -кру -ти -сь!

Мы тебя так долго ждали, Дедушка!
Понемножку подрастали, Дедушка.
Скоро нам рукой помашешь, Дедушка,
Не уйдёшь пока не спляшешь, Де- ду -шка!

**Тәрбияче.** Кыш бабай, балалар белән уен да уйнап ал инде.

**Кыш бабай.** Кызым Карчәчәк, каяле минем тылсымлы таягым, хәзер мин бу шаяннарны өшетәм.

**<u>Уен “Кыш бабай таягы”</u>** ***Музыка 14***

**Кыш бабай.** Һай, җитез балалар икән, берсе дә туңып калмадылар. Булмаса үзегез бер биеп күрсәтегез әле.

**<u>Бию “Бубенцы”</u>** ***Музыка №15***

*Биюдән соң дуңгызлар уртада кала. Кулларында 2019 тоталар.*

**Бүре.** Я, я, нәрсә мактанып уртада торасыз? *(Читкә карап).* Озакламый Кыш бабай белән Карчәчәк китәләр, менә шунда бәйрәм башланачак.

**Кыш бабай.** Тукта, Сорыкай, әнә сәгать 12 тула, беләсеңме нәрсә елы киләчәк 2019 елда?

**Бүре.** Әйдә, Бүре елы килсен ә, Кыш бабай?!

**Кыш бабай.** Ә юк, дустым, менә 2019 елның хуҗалары!

Уй-фикергә хаклык төяп,
Теләкләргә пакълык төяп,
Ниятләргә ныклык теләп,
Килде безгә Яңа ел!

**Ниф-Ниф.** Яңа бәхет, яңа шатлык
Алып килсен Яңа ел!

**Наф-Наф.** Яңа җиңүләре белән
Килсен безгә Яңа ел!

**Бергә.** Яңа ел котлы булсын!

Яңа ел котлы булсын!

**Җыр “Праздник новогодний”** ***Музыка№ 16***

Праздник новогодний снежный и блестящий,
Дед Мороз придет к нам самый настоящий.
Новый год настаёт, весело сверкает,
Новый год, Новый год детвора встречает.

Бусинки на елке засверкали ярко,
Ждут ребят сегодня чудеса, подарки.
Новый год настаёт, весело сверкает,
Новый год, Новый год детвора встречает.

Зайчики, снежинки пляшут возле ёлки,
Ах, какой веселый праздник новогодний.
Новый год настаёт, весело сверкает,
Новый год, Новый год детвора встречает.

**Кыш бабай.** Ай, балалар, сезнең белән бик күңелле булды. Безгә китәргә вакыт та җиткән.
Яңа ел белән!
**Тәрбияче.** Рәхмәт, бабай, сүзләреңә
Бик матур теләкләрең.
Алып килдем дигән идең
Кайда соң бүләкләрең?
**Кыш бабай.** Менә, кызым Карчәчәк, балаларга дигән күчтәнәчләрем салынган капчыгым кая икән? Таба алмыйм.
**Бүре.** Кыш бабай, менә мин урманда бер капчык тапкан идем, ләкин ул ачылмый.
**Кыш бабай.** Ул бит тылсымлы капчык, начар уйлы кешеләргә ачылмый, әйдә миңа ярдәм ит әле, Сорыкай.

*Бүләк тараталар.*

**Кыш бабай.** Сау булыгыз, балалар!
**Карчәчәк.** Әти-әниләрегезне тыңлагыз! Сәламәт, акыллы булып үсегез!
**Бергә.** Яңа ел котлы булсын!
**Балалар.** Рәхмәт, Кыш бабай!
Рәхмәт, Карчәчәк!
Сау бул, Кыш бабай!
Сау бул, Карчәчәк!

**Тәрбияче.** Рәхмәт әйтик чыршыбызга
Матур бәйрәме өчен.

Рәхмәт әйтик кунакларга
Килеп караган өчен.

Яңа елга яңа юлдан
Нык басып, бердәм керик.
Иң изге, саф теләкләрне
Бер-беребезгә телик.

**Әниләр көне.**

**Максат:** Әниләрнең газиз, кадерле кеше булуларын, аларның һәркем өчен бер генә булуын төшендерү; балаларда әниләргә карата кадер-хөрмәт, ярату, олылау хисләре тәрбияләү; гаилә белән бакча арасындагы дуслыкны, хезмәттәшлекне ныгыту**.**

**Чара барышы.**

**1 нче алып баручы.** Әни... Әлеге кыска гына сүз үзендә күпме наз, йөрәк җылысы һәм ятатуны саклый. Аны әйткән саен күңел йомшара, ишеткән саен дөнья ямьләнә. Кадерле әниләр, бүгенге бәйрәмебез сезгә багышлана! Бүген бөтен дөнья әниләр турында сөйли, хәтта әниләргә багышланган махсус «Әни+» телевидение каналы эшли. Анда бөтен тапшырулар сезгә багышланган, кадерле әниләр! Бәйрәмнәрдә кешеләр бер-берсенә бүләкләр бирергә гадәтләнгән. Ә ана кеше өчен сабыеның елмаюлы йөзен күрү, яратуын тоюдан да олырак бүләк буламы соң? Әлбәттә, юк! Шуңа да бу бәйрәмнең иң кадерле бүләкләре – балалар үзләре, аларның сезгә әйтәсе назлы сүзләре, күрсәтәсе һөнәрләре булыр!..

*«Яңалыклар» тапшыруы заставкасы яңгырый.* ***Музыка № 1***

**2 нче алып баручы.** Исәнмесез, хөрмәтле тамашачылар! «Әни+» телеканалы үзенең эшен башлап җибәрә. Эфирда – яңалыклар. Музыка залыннан туры трансляцияне башлыйбыз. Студиябез кунаклары – “Ләйсән” балалар бакчасы балалары. Алар бу очрашуга бик озак әзерләнгәннәр, әниләренә гаҗәеп матур бүләк тә әзерләгәннәр. Алкышлар белән каршы алыйк үзләрен!

***Музыка № 2*** *(Балалар чыга).*

**Искәндәр.**
Дөньяда иң яхшы әни,
Беләсезме, кемнеке?
Белмәсәгез, үзем әйтәм,
Ул әни бит – минеке.

**Айваз.**
Әни кебек булсам иде! –
Аның назлы сүзләре.
Их, яратам әниемне-
Аның нурлы күзләре.

**Динә.**
Әнием минем матур
Күзләре якты, көләч.
Шундый күңелле була
Ул өйгә кайтып кергәч.

**Данил.**
Әнием гел балкып тора
Күктәге йолдыз кебек.
Мин дә тырышам булырга
Газиз әнием кебек.

**Алия.**
Иренә белми әнием,
Көне буе эшләр карый.
Күңелемне юатырга
Син бар бит әле ярый.

**Адель.**
Мөмкин булса, җыеп учларыма
Бирер идем кояш нурларын,
Әни кеше генә кочагында
Назлый белә газиз улларын.

**Роберт.**
В садик нас ведёт за ручку
И целует у дверей
Нет на целом белом свете
Мамочки добрей.
Ну а если мы болеем
Трогает горячий лоб
Добротою мама лечит
Кашель и озноб.

**Газизуллин Искәндәр.**
Кто пришёл ко мне с утра? - Мама.
Кто сказал: "Вставать пора"? - Мама.
Кашу кто успел сварить? - Мама.
Чаю – в чашку кто налил? - Мама.
Кто меня поцеловал? - Мама.
И так сильно обнимал? – Мама.
Кто ребячий любит смех? - Мама.
Кто на свете лучше всех? – Мама.

**Җыр "Рәхмәт, әнием".** ***Музыка № 3***

**1 нче алып баручы:** Телеэфир үзенең эшен дәвам итә. Программада «Көйне беләсеңме?» тапшыруы. Кунакка килгән әниләр,балалар җырларын барыгыз да беләсез микән, сынап карыйк әле.

*«Угадай мелодию» тапшыруы  заставкасы.* ***Музыка № 4***

**2 нче алып баручы:** Көйләр авыр түгел, бик җайлы. Бирегә дүрт әнине чакырыбыз. Көй яңгыргач та, сезгә тиз генә кулыгыздагы  уен коралын уйнатып алырга кирәк. Көйнең исемен әйтеп, җырны сүзләре белән җырлап та күрсәтерсез.

*Танылган мультфильмнардан көйләр.*

1. Крокодил Гена җыры ***Музыка № 5***
2. Буратино ***Музыка № 6***
3. Маша и медведь ***Музыка № 7***
4. Антошка ***Музыка № 8***
5. Зима в Простоквашино - Кабы не было зимы ***Музыка № 9***
6. Простоквашино  ***Музыка № 10***
7. Пусть Бегут Неуклюже  ***Музыка № 11***

**1 нче алып баручы:** Ә хәзер эфирда «Барысыннан да яхшырак!» тапшыруы. Ә үзләренең гаҗәеп бию осталыкларын сезгә балалар тәкъдим итә.

*«Барысыннан да яхшырак!» тапшыруы заставкасы.* ***Музыка 12***

*«Чәчәкләр» биюе.* ***Музыка № 13***

**2 нче алып баручы:** Биюдән тыш алар әле «Без нәфис сүз осталары» һәм “Матур җырчылар”  дип тә белдерәләр һәм әниләргә шигырь бәйләме һәм җыр бүләк итәләр.

**Вильдан.**
Өлгер, җитез минем әни,
Бар эшкә дә җитешә.
Юа, җыя, тегә, бәйли,
Кичкә бәлеш тә пешә.
Туганнарны якын итә,
Әби-бабайны зурлый.
Барысына да өлгерә
Ничек бер дә ул армый?

**Радель.**
Минем әни бу дөньяның
Иң чибәре, сылуы.
Нинди бәхет-
Һәр баланың
Үз әние булуы!
Борчыйсым килми әнине,
Елмаеп,
Көлеп йөрсен.

Иң матур әни икәнен
Бөтен дусларым күрсен!

**Аделина.**
Мама, мама, мамочка,
Лучшая моя.
Мы с тобою, мамочка,
Дружная семья!

Буду тебя слушаться,
Чтобы ты всегда
Знала, что ребенок
Лучший у тебя!

**Дарина.**
Мамочки любимые,
Поздравляем с праздником.
Вы у нас красивые
И такие разные.

Дарим вам объятия,
Песни и стихи,
Солнцем пусть наполнятся
Осенние деньки!

**Жыр "Ах, какая мама"** ***Музыка № 14***

Маму утром разбужу,
"Здравствуй, мамочка!" - скажу.

***Припев:***
Ах, какая мама!
Загляденье прямо!

Очень я тебя люблю,
Ненаглядную мою!

Ты со мною песню спой,
Ведь сегодня праздник твой!

***«Гаҗәп кешеләр»*** *тапшыруы заставкасы.* ***Музыка № 15***

**1 нче алып баручы:** Бәйрәмебезне дәвам итәбез. Киләсе тапшыру **“Гаҗәп кешеләр”** дип атала. Андыйларны әллә кайдан эзлисе юк: әниләребезнең һәрберсе гаҗәп кеше. Кем бер үк вакытта берничә эш эшли ала: ашарга да

пешерә, бала белән шигырь дә ятлый? Машина йөрткәндә үзен сэлфига төшерә...Шул ук вакытта әниләр гаилә бюджетын да күз уңыннан югалтмый. Хәзер бирегә чыгачак әниләр җитезлектә һәм игътибарлылыкта көч сынашачак. Аларга менә бу янчыклардагы акчаларны саный-саный минем сорауларыма җавап бирергә һәм хисапта ялгышмаска кирәк булачак.

*Әниләр бутафор акча «саныйлар», сорауларга җавап бирәләр.*

– Балагызның исеме ничек?
– Балагызның фамилиясе ничек?
– Балагызга ничә яшь?
– Балагызның әтисе ни исемле?
– Балагызның аяк киеме размеры?
– Балагызның туган көне кайчан?
– Балагызның күз төсе нинди?
– Балагыз нинди группага йөри?
– Балагыз ничәгә кадәр саный белә?
- Балагызның яраткан уенчыгын атагыз.

**2 нче алып баручы:** Афәрин! Менә нинди җор телле, җитез безнең әниләр! Ә хәзер әйтегез әле, сез ашарга пешерергә яратасызмы? Мин моны юкка гына сорамадым: эфирда «Тәмлетамак» тапшыруы!

*«Тәмлетамак» тапшыруы заставкасы.* ***Музыка № 16***

**1 нче алып баручы:** Хәзер биредә зур аукцион узачак! Гади аукцион түгел: яшелчә, җиләк-җимешләр аукционы! Әниләргә сюрприз: мин аларның исемен атыйм, ә сез бу яшелчәләрдән, җимешләрдән ризыклар әйтәсез. Соңгы ризыкны атаучы бүләккә ия була!

*Әниләр белән аукцион.Әсбаплар – кыяр, алма, чөгендер, бәрәңге, кишер.*

**2 нче алып баручы:** Ә хәзер бүләк кабул итеп алыгыз – музыкаль оркестр «Күңелле ашханә»!

*Балалар кашыкларда, кыңгырауларда көй уйныйлар.* ***Музыка № 17***

**1 нче алып баручы:** Менә шулай, безнең “Әни+” каналында нинди генә жанрдагы тапшырулар юк! Шуларның иң кызыклысы, мөгаен, “Танцы-биюләр” тапшыруыдыр. Ел саен без иң тырыш, сәләтле балалар белән бик күп биюләр өйрәнәбез. Бүген сезнең игътибарыгызга “Губки бантиком” җырынына кушылып кечкенә балалар биюен тәкъдим итәбез. Рәхим итеп бергәләп карыйк!

*“Губки бантиком” җырына бию.* ***Музыка № 18***

**1 нче алып баручы.** Әниләр, балаларның сезнең белән дә бииселәре килә. Сез тышкы түгәрәкне ясагыз, ә балалар эчке түгәрәккә басарлар. Көй башлану белән кулга-кул тотынып круг буенча биеп йөрибез, ә көй туктагач каршыда торган бала белән кочаклашабыз. ***Музыка № 19***

**2 нче алып баручы:** Менә эфирыбыз ахырына да якынлаша. Шуңа күрә һәр телеканалдагыча һава торышын тыңлап узыйк. “Ләйсән” балалар бакчасы территориясендә аяз һава. Һәркемнең күңелендә Әни дигән якты кояш балкый,күз яшьләре рәвешендәге явым-төшем көтелми, йомшак кына бәйрәм җилләре исә...Балалар әниләрен һәм тәрбиячеләрен тыңлыйлар, шуңа күрә һәркемнең басымы да нормада, тавышлану рәвешендәге геомагнит дулкыннар күзәтелми.Көннәребез һәрчак шундый якты, матур булсын иде! Кадерле әниләр, ныклы сәламәтлек һәм кояштай озын гомер телибез сезгә! Һәм балаларыбыз да бу теләкләргә кушылып, әни турындагы иң матур җырны сезгә бүләк итә.

**“Добрая, милая мама”** ***Музыка № 20***

Ласковым солнышком мама моя
Утром меня нежно будит,
И просыпаюсь с улыбкою я,
Чтоб улыбнуться всем людям.

***Припев:***
Мама, мама, добрая милая мама.
Мама, мама, добрая милая мама.
Светлые песенки мамы моей
Солнечным лучиком льются
И для любимых родных и друзей
Нотки поют и смеются.
***Припев.***

Только бывает порой иногда
Мама немножечко строгой,
Слушаться маму я буду всегда,
Буду во всём ей подмогой.
***Припев.***

**1 нче алып баручы.** Бәйрәмебез ахырында балалардан бүләкләр кабул итегез. (*Бүләкләр тапшыру).*

Изге теләк белән барыгызга
Тәмамлана бәйрәм кичәбез.
Туар көннең кадерен белеп,
Гел шатланып яшәгез!

Гаилә бәйрәме.

“Кош – канаты белән,
Гаилә татулыгы белән көчле”.

**Максат.** Гаиләләр белән элемтәне ныгыту. Балаларда үз милләтенә, аның теленә, гаиләсенә, иленә ихтирамлы мөнәсәбәт булдыру, горурлык хисе тәрбияләү. Гаилә – балалар бакчасы – мәктәп арасындагы дәвамчанлык өзелмәве өстендә эшне дәвам итү.

***Музыка№1*** астында балалар залга кереп басалар.

**“Хәерле көн”** (Әлфия Һадиева музыкасы, Айдар Минһаҗев сүзләре) **җырын җырлыйлар.** ***Музыка №2.*** (Җыр беткәч урындыкларга утыралар).
Йокыдан уянуга мин
Беләм нишләргә кирәк-
Елмаям әти-әнигә
Хәерле көннәр теләп.
*Кушымта:*
Яратам мин, яратам шул
Матур теләк теләргә.
Онытты, дип уйламагыз,
Хәерле көн сезгә дә!

Хәерле көн күршеләргә,
Дуслар, туганнарга да.
Теләктән читтә калмасын
Таныш булмаганнар да.

**1 нче тәрбияче.** Хәерле кич, хөрмәтле кунаклар, әти-әниләр, әби-бабайлар! Бүген бездә гаилә бәйрәме.
Безнең гаиләләр җыелган,
Ял итәр өчен бүген!
Сүзләремнең иң матурын
Әйтмичә мөмкин түгел.
Гаилә! Никадәр шатлык, никадәр тантана бу сүздә! Кеше һәм гаилә. Бу ике төшенчә бер-берсенә шулкадәр тыгыз бәйләнгән ки, кешене гаиләсез, ә гаиләне кешедән башка күз алдына китерүе кыен. Ә нәрсә соң ул гаилә? Ул нәрсәдән башлана? Нигә шулхәтле кадерле, якын сүз ул? Без бүген шул

сорауларга җаваплар табарбыз һәм күңелле ял итәрбез дип ышанып калабыз. Рөхсәт итегез сезне, безнең балалар бакчасына йөрүче балаларның гаиләләре белән таныштырып үтәргә.
(Презентация “Минем гаилә”).

**2 нче тәрбияче.** “Көннең яктылыгы – кояшта,
Күкнең матурлыгы – йолдызларда,
Җирнең гүзәллеге – хатын-кызларда!” – дип яза бөек шагыйләребез безнең әниләребез турында. Чыннан да, тормышыбызны ямьләүче иң шәфкатьле, иң мәрхәмәтле, иң газиз кешеләр ул безнең әниләр. Гаиләнең тату, дус яшәвендә дә ана иң төп урыннарның берсен алып тора.

**Айваз.** Әни сүзе – иң бөек сүз,
Юк аңа һичбер алмаш.
Иң-иң әйбәт кешеләр дә
Әни кебек булалмас!
**Вильдан.** Син, әнием, минем өчен
Бу дөньяда бер генә.
Елмайганда йөзләреңнән
Бар өйгә нур бөркелә.
**Радель.** Әниләр җирдә бердәнбер,
Алыштырмый аны беркем дә.
Әниләрне мактап җырлар җырлыйк
Бәйрәм ясыйк аңа һәркөнне.

***Җыр “Рәхмәт, әнием”.* (А.Минһаҗев сүз., Ә.Һадиева көе).** ***<u>Музыка № 3.</u>***
Битемнән үбеп,
Сабыем, диеп
Уята мине
Әнием сөеп.
*Кушымта.*
Әйдәле, бергә
Шатлыклар телик!
Иң әйбәт әни-
Минем әни бит.
Әни булганда
Өйләр ямьлерәк,

Күлмәкләр матур,
Ашлар тәмлерәк.

*Кушымта.*
Әни булганда
Яшәве рәхәт.
Рәхмәт, әнием,
Сиңа зур рәхмәт.

**1 нче алып баручы.** Безнең әниләребез – дөньядагы иң яхшы кешеләр.Әниләребез белән беррәттән безне тормыш сукмагына алып чыгучы газиз әтиләребез дә бар бит әле. Әтиләр! Әти! Әтием!.. Ягымлы, шул ук вакытта җитди гаилә башлыгы. Балаларының бәхете, гаилә иминлеге өчен ару-талуны белмичә көнне-төнгә ялгап, барлык көчләрен куеп тир түгәләр, күп вакытларын эш урыннарында уздыралар.

**Дарина.** Поздравляю, папочка,
С праздником мужчин!
Поздравляю, папочка,
Ты такой один!

**Адель.** Әтиләр илнең терәге,
Гаиләбезнең йөрәге.
Авырлыкларга бирешми
Әтиләрнең беләге.

**Роберт.** Әти белән әнием –
Иң-иң кадерлеләрем.
Бергә мәңге яшәсеннәр –
Минем иң зур теләгем.

**2 нче алып баручы.** Балалар үз әтиләре хакында гомерләре дәвамында менә ни уйлыйлар:

- 5 яшьтә. “Әтием бөтен нәрсәне белә”.
- 10 яшьтә. “Әти күп әйберләрне белә”.
- 15 яшьтә. “Мин дә әти белгәннәрне беләм”.
- 20 яшьтә. “Дөресен генә әйткәндә, әти берни дә белми”.
- 30 яшьтә. “Әти шулай да кайбер нәрсәләрне белә икән шул”.
- 40 яшьтә. “Әтидән киңәш сорасаң, комачау итмәс иде”.
- 50 яшьтә. “Әтием бөтен нәрсәне дә белә”.
- 60 яшьтә. “Эх, әткәем исән булса, мин аның белән киңәшләшер идем”.

***Җыр “Әтиемә”*** ***Музыка №4***

**1 нче алып баручы.** Безнең барыбыз өчен дә бик кадерле булган әбиләребез, ягъни дәү әниләребез бар. Бу бәйрәмдә олы җанлы, киң күңеллле, йомшак куллы, тәмле телле әбиләребезне зурламаск гаиләбез китек булыр. Әбиләребезнең чал чәчләреннән сыйпыйсы, дөньядагы иң ягымлы сүзләр белән юатасы, мең-мең рәхмәтләр әйтәсе килә.

**Булат.** Иң кадерле, иң хөрмәтле
Булсын җирдә әбиләр.
Әбиләрне кадерләсәк,
Тыныч булыр ил-көннәр.

**Алия.** Әниемнең әнисе
Әбием була минем.
Әби генә түгел әле
Ул минем дәү әнием.

Тәмле ашлар пешерә,
Матур гөлләр үстерә.
Өебезнең нуры ул,
Барыбыздан олы ул!

***Җыр "Әбием, әбекәем"*** (Рөстәм Сәрвәров музыкасы, Рөстәм Бакиров сүзләре). ***<u>Музыка №5.</u>***

Балам дия дия безне
кадерләп үстерәсең.
Әй, матур син, әбекәем
Күзләр тия күрмәсен.

Әй әбием әбекәем
Кояш кебек күнелен
Сәламәтлек бирсен ходай
Озын булсын гомерен.

Өебезнен нуры бит син
Рәхмәт яусын үзеңә
Бәхетле без әбекәем
Син булган өчен генә.

Әй әбием әбекәем
Кояш кебек күнелен

Саләмәтлек бирсен ходай
Озын булсын гомерен.

**2 нче алып баручы.** Бүгенге бәхетле тормыш өчен яраткан бабайларыбызга без бик бурычлы. Сабыйларыбызның татлы йокысы өчен, якты киләчәгебез, аяз күгебез, илебез тынычлыгы өчен мең-мең рәхмәт әйтәбез сезгә, хөрмәтле бабайларыбыз!

**Динә.** Бабай янымда булганда
Бернәрсәдән курыкмыйм.
Анның сүзе миңа закон,
Бабамны гел тыңлыйм мин.
**Роберт.** Славный дедушка родной
Самый добрый дорогой.
Поздравляем мы тебя
Я и вся наша детвора!

***Җыр "Иң шәп бабай"*** (Рөстәм Сәрвәров музыкасы, Рөстәм Бакиров сүзләре).
***<u>Музыка №6</u>***
Сөенеп туймас балачак,
Иң бәхетле балачак.
Бабай белән үткән кичләр
Мәңге истә калачак.

*Кушымта:*
Яратабыз сине, бабай,
Син бит безнең бер генә.
Нурлы йөзле, шат күңелле,
Иң шәп бабай – син генә.

Синең эзләр саклanадыр
Бормалы сукмакларда.
Һәй, бабакай, диябез без
Бик сагынган чакларда.

**1 нче алып баручы.** Безнең өчен иң кадерле һәм газиз кешеләр – әти-әниләр, әби-бабайларыбыз бар. Без алар белән чын күңелдән горурланабыз, чөнки бер гаилә булып, кайгы-шатлыкларны бүлешик, балаларыбыз-оныкларыбыз

өчен сөенеп яшибез. Гаиләдә һәркем бер-берсен кайгыртып, ярдәмләшеп яшәргә, бер-берсенәтаяныч булырга тиеш.

Бүген безнең бәйрәмебезгә берсеннән-берсе оста, тату, матур гаиләләр килгән. Сезне бәйрәмнәрегез белән котлыйбыз. Балаларыгыз сезгә үзләренең һөнәрләрен күрсәтер, сөенеп рәхәтләнеп ял итегез.

**2 нче алып баручы.** Тату гаилә – ил терәге,
Сабый өчен иң кирәге.
Гаилә тату, бердәм булса –
Балалар бәхетле була!

**Галимов Искәндәр.** Әти, әни һәм дә мин –
Безнең тату гаилә.
Дөнья ямьле, яшәү рәхәт
Дуслыкта бөтен хәйлә.

Олы бәхет рәхәтләнеп
Яшәүләре гел бергә.
Насыйп булсын иде безгә
Шатланып яшәү көн дә.

***“Яулыклар белән бию”.*** ***<u>Музыка № 7</u>***

**Аделина.** В день веселый, солнечный
Маму поздравляем мы.
Жизни долгой, радостной
От души желаем мы.
Слушай нашу песенку
Мамочка любимая.
Будь всегда здоровая,
Будь всегда счастливая!

***Җыр “Мамочка милая моя”.*** ***<u>Музыка 8</u>***

1.Мамочка, милая мама моя
Пусть эта песенка будет твоя
Ля-ля-ля-ля,
Ля-ля-ля-ля,
Пусть эта песенка будет твоя

2.Это тебе мой подарок такой
Пой эту песенку вместе со мной
Ля-ля-ля-ля, Ля-ля-ля-ля,
Пой эту песенку вместе со мной.

**Айваз.** Әтиемнең алтын куллары
Күрәп куя карлы юлларны.
Ул булганда җылы өебез,
Ул булганда җырлап йөрибез.
**Газизуллин Искәндәр.** Кто на свете самый сильный?
Папа!
А кто же умный, смелый?
Папа!
Кто веселый, добрый, мудрый?
Папа!
И кто любимый всех на свете?
Папа!
Конечно же все мечтают
Похожим быть на тебя.
Но мы – то с тобой знаем
Твое отражение – это я!
***"Моряклар" биюе.*** ***Музыка № 9***

**Данил.** Әтиемнең кулында
Ялт та йолт утлы каләм.
Тимер дәфтәр өстенә
Яза ул кайнар сәлам.
Кирәк булса эретә
Өч кисәкне бер итә.
Аунап яткан тимерне
Кирәкле әйбер итә.
Челтәр бәйләгән кебек
Ясый ул төрле бизәк.
Минем әтием кебек
Алтын куллылар сирәк.

***Җыр "Будущий солдат»*** ***Музыка № 10***

**Дарина.** «Бабушка любимая
Самая красивая!
Руки золотые,
Глазки молодые
Будь всегда счастливой
Мудрой и красивой.
С праздником родная
Снова поздравляю!

***Бию «Девушки фабричные»*** ***<u>Музыка № 11</u>***

**Вильдан.** Кайда икәнен белми
Әби күзлеген эзли.
Күзлеге бит кулында
Әмма ул аны сизми.

Әби, әби, - дим аңа
Каршысына ук килеп, -
Җайлы булыр эзләргә,
Күзлегеңне ки элек.

Әби күлеген кия,
Үзе елмая, көлә.
- Рәхмәт, табып бирдең, -
Аркамнан сөя-сөя.

**Аделина.** Әбиләрем бар минем
Ә бабаем бер генә.
Бөтен кеше орышканда
Яклаучым да син генә.

***Җыр "Солдат булам".*** ***<u>Музыка № 12</u>***

**Радель.** Дөньяларда яшәү рәхәт
Туганнар бергә булса,
Гаилә учагы һәрвакыт
Безне җылытып торса.

Тормыш җиңел бергәләшеп

Тату торганда.
Янәшәдә эткәй белән
Әнкәй булганда.

Шатлансыннар әткәй-әнкәй
Дәвамчыларын күреп.
Яшик шулай тормышларны
Гөл чәчәкләргә күмеп.

***Җыр “Кояшлы ил”. Музыка № 13***

**1 нче алып баручы.** Имин булып атсын таң кояшы
Йөзегезгә нурлар сибелсен.
Һәр яңа таң сезгә бетмәс шатлыкв
Һәм гомерлек бәхет китерсен!

**2 нче алып баручы.** Хөрмәтле, эти-әниләр, әби-бабайлар! Сезне бәйрәмнәрегез белән котлап, балаларыгыз сезгә көчләреннән килгәнчә бүләк әзерләде. Гаилә бәйрәме булгач, бүләгебез дә сезнең гаиләләрегез өчен.

## Исәнмесез кошкайлар, безнең якын дускайлар!

Максат :

1. Күчмә кошлар турында мәгълүмат бирү.

2.Халык педагогикасына нигезләнеп, яз турындагы белемнәрен арттыру.

3.Кошларга карата шәфкатьлелек хисе һәм мәхәббәт тәрбияләү.

Тәрбияче бүлмәгә балалар белән керә.

Тәрбияче: Исәнмесез, балалар. Әйдәгез, танышып алыйк. Минем кулымда йомгак аны кулына алган кеше яз көне үзенең нәрсә яратуын әйтергә тиеш. Мин язгы тамчылар җырын тыңларга яратам. (Йомгакны балаларга бирә,

Һәркем үзенең нәрсә яратуын әйтә )

Тәрбияче: балалар, бу йомгак нинди төстә? (яшел )

Тәрбияче: Табигатьтә яшел төс кайчан күренә башлый?

- Яз көне, үләннәр яшел төскә керә.

Тәрбияче: Кем миңа яз айларын әйтеп бирә

-Март, апрель,май.

Тәрбияче: “Март-су белән, апрель-үлән белән, май-яфрак белән.” Халык әйтемен сез ничек аңлыйсыз?

-Мартта кар эри , су күп була.

-апрельдә үлән чыга

- майда агачлар яфрак ярып бетерә.

Тәрбияче: Дөрес. Яз билгеләрен искә төшереп үтик әле.

- Тамчы тама. Кар эри. Ташу ага. Үләннәр үсә. Агачлар яфрак яра. Кошлар җылы яктан кайта.

Тәрбияче: Дөрес әйттегез, кошлар җылы яктан кайта. Ә нинди кошлар кайтканын белү өчен сезгә минем табышмакларыма җавап табарга кирәк.Сез әзерме?

1.Кар-кар ,-дип кычкыра,
Язын беренче килә.(Кара карга ).

2. Язын килә, көзен китә,
Оя ясасаң, үз итә.( Сыерчык ).

- Сыерчык турында тагын нәрсә беләсез?
( җаваплар)

1. Борыны озын боты озын,
Камышлыкта көнозын,
Сазлык җирләрдә йөри,
“тату торыйк”,- дип сөйли. (Торна )
Ә торна турынданиләр беләсез?( җаваплар)
2. Кулы юк, балчык ташый,
Балтасы юк, өй ясый.( Карлыгач)
Карлыгач турында да кем сөйли ?

1 бала шигырь сөйли. “Карлыгач” (Г .Тукай )

Күптән түгел безнең тәрәзә капкачын

Оя итте минем сөйгән  карлыгачым:

Ул көн буе аузы белән балчык ташый,

Балчык белән матур итеп оя ясый.

Күп эшләде иренмичә; бара-бара

Чыгарды ул матур-матур балалар да.

Ачыксалар карлыгачның балалары,

Чебен- черки тотып кайта аналары.

Тәрбияче: Бик матур шигырь. Карлыгач балаларына ашарга нәрсәләр алып кайта?

-Чебен –черки.

Тәрбияче: Дөрес. Ә кыш көне чебен-черки һәм башка бөҗәкләр буламы? Алар кая?

- Бөҗәкләр  кар астында калды .

Дөрес , балалар . Кышын бөҗәкләр кар астында кала, кошларга азык табу кыенлаша. Шуның өчен көзен ,алар җылы якка китәләр.

Тәрбияче: Экранга карагыз әле ,анда сез әйткән кошлар барлыкка килгән. Бу кошларны нинди кошлар дип атыйлар?

-Күчмә кошлар.

Тәрбияче: Сез тагын нинди кошларны беләсез?( җаваплар)

Экранда кышлаучы кошлар күрсәтелә

Тәрбияче.

Уен “Күчмә һәм кышлаучы кошлар”

Күчмә кош исемен әйткәндә-кулларын як-якка җәеп хәрәкәт итәләр; кышлаучы кошлар исемен әйткәндә- чүгәләп утыралар.

Сыерчык  боегып керә.

Тәрбияче. Кошчыгым сиңа ни булды? Сайрап күңелләрне күтәрәсе урында ник  син бик күңелсез?

Сыерчык. Мин  сезне сагынып ерактан очып кайткан идем. Минем ояма башка кошлар кергән. Инде нишлим?

Тәрбияче. Тукта әле кошкаем, кайгырма. Хәзер балалар белән без сиңа ярдәм итәрбез, сиңа бик матур оя ясарбыз.

Балаларның мөстәкыйль эше(  Кайчы белән эшләү кагыйдәләрен искә төшерү,сыерчык  оясы ябыштыру)

Тәрбияче. Балалар, ясаган ояларыгызны сыерчыкка күрсәтегез.Сыерчыккай безнең балаларның ясаган оялары ошыймы?

Сыерчык. Рәхмәт, дусларым, бик ошый. Бу ояларны дусларыма да күрсәтим әле. Алар да шатлансыннар. Ә сез кошлар белән үзегезне ничек тотарга кирәген беләсезме?

- Кошларны рәнҗетмә!
- Аларның ояларын туздырма, йомыркаларын алма!
- Яз көне кошларга оя ясарга онытма!
- Урманда тавышланып йөрмә, әни кошлар ояларын ташлап китмәсен!

Сыерчык. Бик яхшы , дусларым. Мин сезнең әдәпле, яхшы күңелле балалар икәнлегегезгә ышандым, җәй көне тагын очрашырбыз әле. Сау булыгыз!

(Сыерчык китә).

Тәрбияче.Без бүгенге шөгыльдә нәрсәләр турында сөйләштек.(йомгаклау)